

АЙНЫСЫН АВЫЛ

Бер ел эчендә Россия авылларында эшкечелектән интегүчеләр саны 7 процентка арткан

> 5

КОЛАГЫННАН КҮРЕНӘ

Татарстанда шәхси хуҗалыклардагы малларны исәпкә ала башладылар

> 16

ЯЗУЧЫ СҮЗЕ

Ркаил Зәйдулла белән милләт һәм әдәбият турында зур әңгәмә

> 18–19

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 20 (28987) | Җомга | 10 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

REUTERS.com

ҖИР ЯРАСЫ

ТӨРКИЯ ҺӘМ СҮРИЯ ФАҖИГАСЕ БӨТЕН КЕШЕЛЕКНЕ БЕРЛӘШТЕРДЕ

Бер мизгелдә хәрабә хәлендә калган шәһәрләр, җимерелгән йортлар, вакытсыз өзелгән гомерләр, югалту ачысы... Атна башында Төркия һәм Сүриядәге җир тетрәүләр йокыга тала башлаган дөньяны сискәндереп уяткан төсле булды. Ничек тә җир ярасын ямыйсы, булышасы иде хәзер! Бу фаҗигадән Татарстан да читтә калмады. Кешелек кабат берләшү һәм бердәмлекнең нинди кыйммәткә ия булуын дәлилли алды төсле. Фаҗига сабагы бәрабәренә булса да... «ВТ» хәбәрчесе җир тетрәү шаһитлары белән аралашты һәм вазгыятьне белеште.

> 7

Ишетми калмагыз

Дәүләт Думасы үз бурычын үтәгәндә һәлак булган хәрбиләрнең хатыннарына (ирләре дә булырга мөмкин) максималь социаль ярдәм чараларын билгеләгән законны берьюлы икенче һәм өченче укылышта кабул иткән. «РИА Новости» хәбәренә караганда, төзәтмәләр «Ветераннар турында» законга кертелә.

Бу чара һәлак булган хәрби хәрәкәт ветераннарының хатыннары яки ирләренә, кабат никахка кермәгән очракта, социаль яклауны көчәйтүне күздә тота. Алар айлык акчалата түләү алачак. Моңарчы һәлак булган хәрбиләрнең хатыннары, балалары белән генә түгел, башка гаилә әгъзалары белән, әйтик, әти-әниләре белән бергә яшәгән очракта, әлеге ярдәм чараларыннан мәхрүм иде.

Узган елда Республика клиник хастаханәсе, ерактагы авылларда яшәүчеләргә диспансеризация үткәрү өчен, яңа мобиль медицина комплексына ия булган. Шулай итеп, табиблар берничә ай эчендә районнарда 8191 кешене кабул итәргә өлгергән. Мобиль комплекс көненә 90лап сырхауны карау мөмкинлегенә ирә. РКБга ул «Сәламәтлек саклау» һәм «Демография» илкүләм проектлары буенча кайтарылган. Хастаханәнең иске мобиль комплексы исә, Татарстан Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Луганск Халык Республикасында калган.

Исегезгә төшерәбез: «Сәламәтлек саклау» һәм «Демография» илкүләм проектлары, Россия Президенты Владимир Путин Указына туры китереп, 2019 елдан бирле гамәлгә ашырылып килә.

Язгы авыл хуҗалыгы ярминкәләре 18 мартта башланачак. Бу хакта авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров хәбәр итте.

«Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов тарафыннан язгы ярминкәләрне үткәрү көннәре расланды. Алар 18 марттан 22 апрельгә кадәр үткәреләчәк, – диде министр. – Бу азык-төлеккә бәяләр артуны тоткарларга һәм республика халкын авыл хуҗалыгы продукциясе һәм көндәлек азык-төлек товарлары белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирде».

Узган ел 19 марттан 23 апрельгә кадәр узган ярминкәләрдә 2,1 млрд сумлык продукция сатылган.

Балык Бистәсе районында балаларына 8 елдан артыграк алимент түләмәгән 46 яшьлек анага хөкем карары чыгарылган. Ул 7 айга төзәтү эшләре башкаруга хөкем ителгән, хезмәт хакының 5 процентын дәүләт файдасына тотып калачаклар. Татарстан прокурорының өлкән ярдәмчесе Руслан Галиев әйтүенчә, бу хатын-кыз инде 2014 елның июлендә үк хезмәт хакының яисә башка кеременең ким дигәндә яртысын өч баласын карау өчен түләргә тиеш булган. Әмма алимент түләүдән качып йөргән. Административ җаваплылыкка тартудан да мәгънә булмаган. Узган елның декабренә алимент буенча бурычы 1,6 миллион сумга җиткән. Нәтиҗәдә җинаять эше кузгатылган. Судта ул үз гаебен таныган.

Районнарда ни хәлләр?

Чаллы

Быел Чаллыда 230 меңнән артык машина исәпләнә. Бу сан узган ел белән чагыштырганда 4 меңгә күбрәк. Уртача алганда, 1 мең кешегә 431 транспорт чарасы туры килә. Бу – Россиядә иң югары күрсәткеч. Мисал өчен, Мәскәүдә – 386, Татарстанда – 352, Казанда – 362. «Саннар алдамый. Игътибар итегез, 171 гектар җирдә ярты миллион кеше яши. Машиналар саны да шактый. Бу, бер яктан, кешеләрнең матди мөмкинлекләре булуны күрсәтсә, икенче яктан, машиналар арткач, юл һәлакәтләре дә арта», – диде шәһәр мэры Наил Мәһдиев Чаллы хакимиятендә юл йөрү иминлеге мәсьәләләренә багышланган утырышта.
(«Шәһри Чаллы»)

Алексеевск

2023 елда Алексеевск районында икмәк пешерү комбинаты төзеләчәк. Бу хакта Татарстан кулланучылар җәмгыятьләре һәм кооператив вәкилләренең 2018–2022 ел нәтиҗәләре буенча XX гомуми отчет-сайлау җыелышында район башлыгы Сергей Демидов хәбәр итте. Алексеевскида икмәк пешерү юнәлеше районда әзерләнүче продукциянең 50 процентын алып тора. Узган ел районда 1617 тонна икмәк пешерелгән. Сергей Демидов сүзләренчә, яңа икмәк пешерү комбинаты өчен мәйданчык сайланып куелган.
(«Татар-информ»)

Чирмешән

Түбән Кармалка авылында модульле фельдшер-акушерлык пункты (ФАП) ачылды. Бу авыл өчен бик кирәкле бинаны бәйрәм ясап файдалануга тапшырдылар. «Сезнең өчен мин дә бик шат. Фельдшер көн дә кирәк. Авылда яшәүчеләрнең тормыш шартларын яхшырту өчен тырышучы Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка, тәэзүчеләргә бик зур рәхмәт», – диде район башлыгы Рамил Айбатов. «Бу көнне мин дә, авылдашлар, аеруча олы яшьтәгеләр, бик түземсезләнеп көттек. Элеккеге белән чагыштырлык та түгел», – диде ФАПта эшләячәк фельдшер Людмила Щукина. Бу – районда инде ундүртенче яңа ФАП. Түбән Кармалкада 256 кеше яши. Бирегә күптән яңа бина ачылганы булмаган.
(«Безнең Чирмешән»)

Актаныш

Яңа Кормаш авылында Әфганстанда интернациональ бурычын үтәгән батыр солдат Илдар Хафизов һәм Айдар Акмалов яшәгән йортка истәлек тактасы куелды. Татар Суыксуы авылында да батыр авылдашларын искә алдылар. Хәзер Әфган сугышы ветераны Илфак Авзалов исемен мәктәпкә аяк баскан һәркем хәтерендә яңартачак, уку йортына керү өлешенә аның исеме уеп язылды. Бу чараларда район җитәкчеләре, авыл халкы, районның Әфганчылар оешмасы ветераннары һәм башка җәмгатьчелек катнашты.
(«Актаныш таңнары»)

ФӘНГӘ АКЧА ЖӘЛ ТҮГЕЛ

Былтыр Татарстанда фәнни эшчәнлеккә еллык чыгымнар тәүге тапкыр 20 миллиард сумнан артып киткән. Безнең өчен яңа технологияләр һәм инновацияләр кебек сүзләр дә күптән ят түгел инде. Тик яңа уйлап тапкан эшләнмәләрне кулланышка кертүдә кыенлыклар бар. Бу хакта галимнәр үзләре әйтте. Татарстан Фәннәр академиясендә Россия фәне көне уңаеннан тантаналы чара узды.

tatarstan.ru

Россия фәне көненә багышланган чаралар кысасында, республика башлыгы Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты объектларын карады. Университет ректоры Рафис Борһанов сүзләренә караганда, вузда белем алырга теләүчеләр саны елдан-ел арта. Бүген югары уку йортында бакалавриат, магистратура һәм аспирантура программаларында 3,8 меңгә якын кеше укый. Былтыр уку йорты Forbes версиясе буенча Россиянең иң яхшы югары уку йортлары рейтингына кергән.

Утырышта узган елга йомгак ясап, алдагы эшләр турында сөйләштеләр. Чарада Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә катнашты. Рөстәм Миңнеханов җыелышны Фәннәр академиясе мәйданчыгында уздыруны республиканың бөтен фәнни җәмәгатьчелеге өчен мөһим булуын билгеләп үтте. Ул Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында академиянең республикадагы күпмилләтле халыкларның мәдәни мирасын саклауга керткән өлешен дә югары бәяләде.

– Россия фәне көне Татарстан өчен зур әһәмияткә ия, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Казанда XIX гасырда ук барлыкка килгән әйдәп баручы фән мәктәпләре республиканы аннан читтә дә танытты. Хәзерге буын Татарстан галимнәре бу эшне лаеклы рәвештә дәвам итә.

Коры сүзләр түгел бу! Тәбәкләрнең фәнни-технологик үсеше илкүләм рейтингында республика 5 нче урында тора. Бу – Татарстанда эшләүче 13 мең галимнең казанышы. Тагын бер дәлил: республиканың тикшеренү учреждениеләре «Фән һәм университетлар» илкүләм проектының төп чараларында уңышлы катнаша.

– Татарстанда фән һәм инженер кадрлары әзерләүгә гадәттәгечә зур игътибар бирелә. Икътисадның югары технологияле тармаклары өчен квалификацияле белгечләрне укыту ике фәнни-укыту үзәгендә һәм алдынгы университетлар мәйданында оештырылган өч инженерлык мәктәбендә алып барыла. Яшь галимнәр саны буенча Татарстан илкүләм күрсәткечләрне дә уздыра. Россиядә ул 44 процент тәшкил итсә, бездә – 60 процент, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Нәтиҗәле эшләү өчен төп фондны яңарту да кирәк, әлбәттә. Бу җәһәттән, республикада әйдәп баручы фәнни-белем бирү оешмаларында җиһазларны яңарту эшенә керешкәннәр дә инде. Республика башлыгы әйтүенчә, Татарстанда фәнни эшчәнлеккә еллык чыгымнар тәүге тапкыр 20 миллиард сумнан артып киткән.

Шунысы куанычлы: яшь галимнәр республикада үзләрен уңайлы хис итәләр һәм аңлы рәвештә фәнне сайлыйлар. Билгеле булганча, «Студентлар стартапы» бөтенроссия бәйгесендә Татарстан җиңүчеләр саны буенча икенче урын алды.

– Бүген республикада фәнни эшчәнлеккә карата кызыксыну уяту өчен төрле чаралар гамәлдә. Алар арасында грант һәм стипендия программалары, фәнни бүләкләр бар. Безнең бурыч – әлеге ярдәм чараларын алучылар арасында көндәшлекне арттыру. Моннан тыш, Татарстанда фәнни эшчәнлекне коммерцияләштерү өчен дә уңайлы шартлар бар, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Аерым алганда, республикада ике махсус икътисадый зона, биш алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре, технопарклар гамәлдә. Күптән түгел генә республикада тагын бер заманча мәйдан барлыкка килде. Федераль университет КАМАЗ белән берлектә төзегән стартап-студия укучылар һәм фәнни-педагогик хезмәткәрләр арасында лаеклы урын алачак, дигән ышаныч белдерде Рәис.

Тармактагы кимчелекләргә дә төртеп күрсәтте ул. Республика башлыгы фикеренчә, ирешкән уңышларыбыз никадәр генә зур булса да, ил алдында торган бурычларга җавап бирерлек дәрәҗәдә кадәр үсәргә кирәк. Бу уңайдан былтыр Татарстанның фәнни-белем бирү тармагын җентекләп өйрәнгәннәр. Күрше төбәкләрдәге һәм илкүләм тәҗрибәне дә өйрәнгәннәр. Әлеге эшнең нәтиҗәсе буларак, 2030 елга кадәр республиканың фәнни-технологик үсеш стратегиясен һәм дәүләт программасын әзерләгәннәр.

– Татарстанның фәнни-белем бирү комплексы өр-яңа үргә менәргә тиеш, – диде Рәис. – Иң мөһиме – куелган бурычларны үтәүне тәэмин итү. Безнең «Татнефть», СИБУР кебек компанияләр, катлаулы бурычларны хәл итү өчен, югары уку йортлары һәм тикшеренү учреждениеләре ярдәмендә оешкан фәнни-технологик мөмкинлекләрне куллана. Сер түгел, күпчелек чит ил технологияләре бездә юк, шуңа күрә бу өлкәдә бәйсезлекне тәэмин итү мөһим. Монда җитди эштән гайре бернәрсә дә барып чыкмаячак. Безнең предприятиеләр моны аңлады инде!

Татарстан Фәннәр академиясе президенты Мәкъзүм Сәлахов та, фән өлкәсе белгечләре һәм предприятиеләр бергә эшләргә тиеш, дигән фикердә. Инновацияле эшләнмәләр никадәр тизрәк кулланылыш тапса, шулкадәр яхшырак.

– Яңа технологияләрне гамәлгә кертүгә бөтен җаваплылыкны галимнәр җилкәсенә генә аударып калдыру дөрес түгел. Моның өчен махсус компанияләрне җәлеп итәргә кирәк, – диде ул.

Мәкъзүм Сәлахов фикеренчә, безнең илдә инновацияләр һәм яңа уйлап табылган эшләнмәләргә кытлык юк. Ә менә аларны кулланышка кертү – икенче мәсьәлә. Академия җитәкчесе сүзләренә караганда, дөньякүләм гамәлгә кертелгән яңа эшләнмәләрнең нибары 0,3 проценты безнең илгә туры килә, АКШта, мәсәлән, әлеге күрсәткеч 36 процент тәшкил итә. Моны Россиядә галим өстәленнән сәнәгать предприятиесенә кадәр әзлексез чылбыр булмау белән аңлаттылар. Оешмаларга әзер продукт кына кирәк шул, дип тә зар белдерде галимнәр.

Очрашуда Рөстәм Миңнеханов фән һәм техника өлкәсендә Татарстан дәүләт бүләкләрен дә тапшырды.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Фәнне үстерүдәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең фәнни юнәлеш җитәкчесе **Гречкин** Александр Николаевич Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» I дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Физик культура һәм спортны үстерүдәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Идел буе физик культура, спорт һәм туризм дәүләт университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең «Су спорты төрләре сарае» укыту-спорт комплексы директоры **Баһаветдинов** Альберт Шамил улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Казан дәүләт медицина университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең кафедра мөдире **Зубков** Алексей Юрьевичка Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы һәм коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралу чорында медицина ярдәмен оештырудагы казанышлары өчен «Алексеевск район үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш медицина шәфкать туташы **Аляшева** Ирина Гавриловна **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Лука Крымский медале** белән бүләкләнде.

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» БҮЛӘГЕН ОТКАН ӘНИСӘ ГАТИЯТОВА:

«СЕЗНЕҢ БҮЛӘКЛӘР БӘРӘКӘТЛЕ БУЛА»

«Үзеңә чыккач, ышанасың икән!» Редакциябез абунәчеләр арасында уздырган лотерея бәйгесендә җиңүчеләр әнә шулай дип сөенде. Кайберләренең мондый бүләкне беренче генә отуы түгел. Суыткыч иясе Әнисә апа Гатиятовага «Ватаным Татарстан» 25 ел элек кухня комбайны бүләк иткән. Бәхет бер килсә, килә бит ул!

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бәйгедә 43 районнан барлыгы 986 абунәче катнашкан иде. Җиңүчеләрне котларга иганәчебез – «Северный морской путь» банкы АҖнең республика филиалы идарәчесе Рамил Кашапов та килде.

– Узган ел ахырында башланган, араларны җылыта торган бәйгегә нәтиҗә ясыйбыз. Җиңүчеләр гадел рәвештә сайлап алынды, – диде «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррир урынбасары Илнар Хөснуллин бүләк тапшыру тантанасында. – Бу – безнең быелгы бәйгеләрнең берсе генә. Быел газетабызның оешуына 105 ел тулуга багышланган чаралар башланып китте. Күптән түгел балалар арасында уздырылган бәйгегә йомгак ясадык. Бүген сезне кунакка дәштек. Киләсе атнада 60 нчы мәртәбә Муса Җәлил истәлегенә «Ватаным Татарстан» гамәлгә куйган көрәш бәйгесе уза. Алга таба да чаралар узачак. Бергә булыйк.

Ул шулай ук федераль банкның милли басма белән хезмәттәшлек итүе өчен иганәче Рамил Кашаповка да рәхмәтен белдерде. «Сез финанс мәсьәләләре генә түгел, татар халкының рухи тормышы турында да уйлыйсыз», – диде хезмәттәшебез. Сүз уңаеннан, банкның Казандагы филиалы ачылуга ике ел тулган икән. Кыскасы, ике бәйрәм бергә туры килде. «Без катлаулы вакытта ачылдык, бизнес безне кабул итте. Шушы вакытта без эшкуарлык белән генә түгел, сәнгать, журналистлар белән танышырга өлгердек. Биредә олысы да, кечесе дә үз республикасын ярата. Татарстан һәркемне үзенә тартып тора», – диде Рамил Кашапов.

Мультиварканы Кукмара районының Зур Сәрдек авылында яшәүче Гөлнара Хәсәновага тапшырдык.

– Газетагызны 1979 елдан – мәктәпкә укырга кергәннән бирле укыйм. Мондый бәйгеләрдә катнашып, квитанцияләрне җибәреп барам. Газетада үзебезнең район, авыл җирлеге турында язган материаллар чыкса, күңелгә тагын да рәхәт була, – диде ул. – Бүләк отканымны белгәч, башта үзем дә ышанмыйча тордым. Сер түгел, халык мондый чараларның гадел булуына бик ышанмый. Ә сезнең бәйге гадел икән.

Бер кызыклы факт та бар. 1990 елда Гөлнара ханым белән аның булачак иренең фотолары газетабызда басылып чыккан. Фото астына: «Яшьләр, укып бетереп, авылга эшкә кайтырга, авыл хуҗалыгында хезмәт куярга планлаштыралар», – дип язганнар. Нәкъ шулай килеп чыккан да!

Микродулкынлы бүләк Зәй шәһәренә кайтып китте. Аны Рәмзия Хәбибуллина откан иде. Бүләкне Казанда яшәүче улы Рәмис килеп алды.

Иң зур бүләк – суыткыч! Ул Саба районының Олы Кибәче авылында яшәүче 64 яшьлек Әнисә апа Гатиятовага эләкте. Редакциягә ул ире Мөхәммәтхан абый белән бергәләп килгән. Бергә яшәүләренә – 40 ел. Мөхәммәтхан абый – механизатор, Әнисә апа гомер буе фермада эшләгән.

Шунысы кызык: Әнисә апа 1998 елда газетабыз оештырган бәйгедә кухня комбайны откан булган. 25 ел вакыт узса да, җәйланма эшли икән әле.

– Сезнең бүләкләр бәрәкәтле була. Минем кулым җиңел. Газеталар уздырган бәйгеләрдә катнашып, тегермән, 5 мең сум акча отканым бар. Икенче юлы башкаларга чыксын инде, – диде ул. – Ел саен дистәдән артык газета-журнал алдырабыз. Телефон заманы булса да, халык газетадан аерылмый. Журналистларны фотодан гына күрсәк, хәзер үзегезне күреп китәбез.

Саба районының Шәмәрдән авылында яшәүче 12 яшьлек Әминә Закирҗанованы да сөендердек. «Северный морской путь» банкының республика филиалы идарәчесе Рамил Кашапов белән аңа махсус бүләк – «акыллы» колонка һәм акча салынган банк картасы тапшырдык. Әле күптән түгел генә Әминә Махсус Олимпиаданың Казанда узган Бердәм Уеннарында фигуралы шуу буенча беренче урынны яулады. Биш яшеннән спорт белән шөгыльләнгән баланың беренче зур җиңүе бу! Әминә катлаулы программаны югары дәрәҗәдә башкарып чыккан. Бу хакта газетабызда да язган идек. Әнисе Фәридә әйтүенчә, Әминә – герой ул! Кечкенә кызның тырышлыгы һәм ихтыяр көченә иганәчеләребез дә битараф калмаган. «Синең белән горурланабыз. Сиңа шушы музыкаль колонканы бүләк итәбез. Ул сиңа әкият сөйләр, дәрес әзерләргә булышыр, кичен җырлар да җырлар. Киләчәгең матур булсын!» – диде Рамил Кашапов бүләкне тапшырганда.

Сәрия МИФТАХОВА

tatarstan.ru

Көндәш түгел, теләктәш

Дәүләт Советында

Бер-береңнән өйрәнергә беркайчан да соң түгел! Минск өлкәсенең депутатлар Советы делегациясе белән очрашуда Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин шулай диде. Узган ел Татарстан һәм Минск өлкәсе закон чыгаручылары хезмәттәшлек турында килешү имзалаган иде.

– Безнең өчен Татарстан һәм Минск арасында үзара хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре бик кадерле. Икътисадый, мәдәни тормышта уртак якларыбыз күп. Татарстан һәм Белоруссия икътисады тыгыз бәйләнгән. Бу – нефть химиясе, машина, трактор төзелеше дә, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү дә. Татарстан сәнәгате соңгы елларда зур үсеш кичерде. Моңа шул исәптән сезнең ярдәмегез, сәнәгатьчеләрегез һәм икътисадыгыз ярдәмендә ирешә алдык. Бүгенге шартларда икътисадый, мәдәни, рухи мөнәсәбәтләрне җәйга салу һәм ныгыту, авырлыкларга каршы тору өчен берләшү бик мөһим, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Парламент башлыгы хезмәттәшлекнең үсеш юнәлешләреннән берсе итеп ике якның да җитештерү предприятиеләрен атады.

– Авыл һәм җитештерү сәнәгате өчен техниканың 60 процентнан артыгын сездән алабыз. Безнең предприятиеләр дә Белоруссия өчен продукция җитештерә. Узган ел икътисад өчен гади булмады. Илдә, республикада җитештерү күләменең 17–20 процентка кимүе фаразланган иде. Әмма без сынатмадык. Элемтәбезнең ныклы һәм ышанычлы булуына тагын бер кат инандык. Бер-береңнән өйрәнергә беркайчан да соң түгел. Шулай килеп чыккан проблемаларны чишү юлларын эзлибез, – диде ул.

Минск өлкәсенең депутатлар Советы рәисе Наталья Якубицкая да, парламентлар арасында имзаланган килешү ике як өчен дә ныклы нигез булачак, ди.

– Бу кыска вакытлы гына хезмәттәшлек түгел, без бик тыгыз һәм җитди эшләячәкбез. Татарстан һәм Белоруссия арасындагы элемтәләр елдан-ел ныгый гына бара. Төбәкләр арасында товар әйләнеше 24,9 процентка үсте. Безгә сезнең икътисадта тотрыклылыкны тәэмин итүегез дә, төрле милләт кешеләре арасында дуслыкны саклау тәҗрибәгез дә кызыклы, – диде Наталья Якубицкая. – Бүген безнең бурыч – үзара ярдәм, хезмәттәшлек. Безнең арада көндәшлек булырга тиеш түгел. Без бүген икътисадта инвестицияләрнең өстенлекле булуын аңлыйбыз. Безнең өчен инвесторларның ике төбәккә дә килүләре бик мөһим. Моның өчен булдыра алганча төрле шартлар тудырабыз. Сезнең белән килешү дәвамлы булыр дип ышанам.

Ләйсән САФИНА

Әйтеп кенә бактым

«Миннән дип әйт»

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Беркөнне бер проблема килеп чыкты. Проблема дип, бер уйлаганда, аның әллә ни кот очарлыгы да юк инде. Бер дусны сырхауханәгә урнаштырырга, яхшы табибка күрсәтергә кирәк иде. Зур кешеләрне борчыйсы килмәде, дус-ишләр белән киңәшкәндә, берсе: «Минем бер таныш бар, любой проблемаңны хәл итә ала!» – дип куйды. Телефон номерын да бирде. «Миннән сәлам әйт!» – дип тә өстәде. Шалтыраттым моңа, гозеремне әйтеп бирдем. Бераз уйланып торды да биш-ун минуттан шалтыратырга кушты. Биш минут та узмады, үзе шалтырата бу: «Фәлән больницага бар, шул кешене тап, телефоны шундый, миннән дип әйт», – диде.

Бардым, проблема хәл ителде. Әсхәткә рәхмәт әйтеп шалтыраттым. Әллә ни исе китмәде: «Гозерең булса, оялып йөрмә», – дип кенә куйды.

Телефоннан сөйләшү – бер хәл, минем аның үзен күрәсе килә иде. Нindirәк кеше икән, кем әйтмешли, «всемогущий» егет. Очраштык без Әсхәт белән, бер чор кешеләре булып чыктык. Заманында ул Казан рестораннарының берсендә директор булып эшләгән икән. Татарстанның шактый зур түрәләре ашарга аңа йөргәннәр. Йөрмәсләр иде, ресторанда аш-су бик тәмле, хезмәт күрсәтү иң югары дәрәҗәдә. Ул заманда кибет-ресторан директорлары үзләре дә бик дәрәҗәле кешеләр, җәмгыятьнең каймагы иде. Уртакул җитәкчеләр хәл итә алмаган мәсьәләне сәгате-минуты белән хәл итә иде алар. Һәм, әлбәттә, үзләре дә бик муллыкта яшәделәр.

Ни гаҗәп, яңа танышым Әсхәт андыйлар рәтенә керми икән. Гадәти шәһәр квартирасында яши. Кемгәдер булышудан тәм таба, аерым бер рәхәтлек хисләре кичерә кебек тоелды ул миңа. Сөйләшеп утыра торгач, шуны белдем: балачагы шактый авырлыкта узган Әсхәтнең, яшьли ятим калган, үз тормышын үзе корырга өйрәнгән. Бәхетенә дип әйтимме, тормыш юлында аңа таяныч булырдай кешеләр гел очрап торган.

– Үзең яхшы булгангадыр, – дип сүз кыстырган булам.

– Кем белгән инде аны, – ди Әсхәт.

Дустымның Әсхәт турында «любой мәсьәләне хәл итә ала» дигән сүзләре искә төште дә:

– Сиңа нәрсәгә кирәк болар? – дидем.

Бу соравым аңа бераз кыргыйрак булып тоелды, ахрысы. Миңа айдан төшкән кешегә караган кебек карап куйды. Аннан соң:

– Бер үк җирдә яшибез бит, – ди. Барыбер аңлап бетермәдем мин Әсхәтне.

«Кеше бер-берсенә дус, иптәш һәм туган» дигән сүзләр бик модада булган заманда тәрбияләнсәм дә, Әсхәт үзе дә миңа айдан төшкән кеше кебек тоелды. Теге уртак дустыбыз әйтмешли, кемгәдер ярдәм иткән өчен берәүдән дә берни сорамый икән ул. Рәхмәт әйтсәң, шул җитә, дип әйтә, имеш.

Саубуллашыр алдыннан:

– Һаман эшлисеңмени әле? – ди.

– Хәзергә кумыйлар үзе. Ну, барыбер лаеклы ялга чыгасы килә.

– Кумагач, эшлә инде. Үз аягыңда йөрисең бит әле. Эштән киткәч, пенсияң күпме булыр икән соң?

– Әллә тагын...

– Син кайсы районда яшисең әле?

– Идел буе районында.

– Алайса, Пенсия фондына бар да, шул кабинетка керең, Людмиланы күр һәм пенсияңне исәпләт. «Мин Әсхәттән» дип әйт, яме?

Раббым, кемнәрең генә юк!

АКЧА-МАКЧА

2006 елда шундый исемдә язма бастыргынмын икән. Интернет киңлекләрендә ул һаман да әйләнеп йөри. Үзем язган кульязманы югалтканмын инде, кыскартылып интернетка эленгән өлешен генә карадым. Анда мин озакламый капитализмның үз-үзен җимерәчәген фаразлаганмын, «Якындагы еллар рубльнең дә, долларның да һәм башка кәгазь валюталарның да «буш куык», бер нәрсә белән дә ныгытылмаган гапгадәти кәгазьләр генә икәнлегераслар шикелле», – дигән юллар язганмын, «Долларның һәм шуңа бәйле рәвештә бөтендөнья икътисадый кризисының башлануы – иң беренче чиратта, Россиядә икътисадый фаҗига башланды дигән сүз», – дигән фикер әйткәнмен.

2008 елда әле тагын «Алтын-малтын» дигән язма да әзерләгәнмен. Анысында: «Озаклямый очын очка ялгап баручы безнең кебек миллионнарның тәмам бөләчәге, товар кытлыгы башлану, либераль икътисадлы капитализмның җан тартышуы һәм инде, ихтимал, Өченче Бөтендөнья сугышының якынаюы... Көтәргә мөмкин булган нәтиҗәләр якынча менә шундыйрак», – дип игълан иткәнмен. Моннан унбиш-унҗиде еллар элек ул фикерләрне әйтә алуыма бик гаҗәпләнмим, чөнки бөтен буш вакытымны акча-финанс мәсьәләләрен өйрәнүгә багышлаган идем. Редакторлар ничек бастырганнар, шунысы бераз гаҗәбрәк. Дөрес, бик кыскартып бирделәр язмаларны, чөнки «тиле» фикерләр мул сибелгән иде. Әмма ул чакта юләр кеше идеяләре булып саналырлык «товар кытлыгы» да, «капитализмның җан тартышуы» да, «Өченче Бөтендөнья сугышының якынаюы» да бүгеннең чынбарлыгы инде. Без автомобильләр ремонтлата алмыйбыз (запчастьлар дефицит), чит ил паспорты ясау туктатылды (ярты тырнак кадәр чипларга кытлык), совет чорында да күрелмәгән йод дефициты, аспирин җитмәүчелеге көн тәртибенә килеп басты. Дефицит киләчәктә үсәчәк һәм бер бездә генә түгел. Хәзер бит дәүләтләр аерым товарларны яисә чималны бер-берсенә сатуны чиклиләр яки чикләү белән янийлар. Американнар Кытайга чиплар сатуны туктата, Кытай АКШны кояш станцияләре өчен кирәкле компонентлардан мәхрүм итү белән куркыта һәм башкалар. Болар дефицит тудырмый кала алмыйлар, билгеле.

Бүген илдә-көндә, дөньяда бара торган вакыйгалар аек акылга сыймаслык булып тоелмыймы сезгә? Әле ун ел элек кенә боларның берсе дә юк иде бит. Хәтта бер ел элек, ун айлап вакыт узуга, Казанда бомбадан качу урыннары әзерли башлаячаклар, ракета һәм дрон һөҗүмнәре бик реаль нәрсә булып тоелачак, дисәң, кулыңа психиатрик клиникага юллама тоттырачаклар иде. Бу сәерлекләрнең, лидерларның үзләрен «түбәсе кыйшайган» адәмнәр кебек тотуларының артында «акча» дигән көндәлек кулланыла торган нәрсә ята. Акчаның җитмәве түгел, аңа ышаныч бетү тудыра фаҗигале хәлләрне. Кулында долларлар булу синең үзең теләгән товарны сатып ала алачагыңны аңлатмый инде. Башка валюталар да киләчәктә синә матди яктан тәэмин ителүне гарантияләми. Бу юллар авторы үнҗиде ел элек игълан иткән доллар кризисы башланды.

Бер-ике көн элек кенә атаклы икътисадчы, кризисларны төгәл фаразлавы белән танылган Нуриэль Рубини «Financial Times»-тагы колонкасында Америка долларының якындагы ун ел эчендә өстенлеген югалтып бетерәчәген фаразлады. Гафу итегез, без Рубинидан күпкә алдарак татар матбугатында әйттек ул фикерне. Без хәтта әле хәзер дә Нью-Йорк университеты профессорын төзәтүдән курыкмыйбыз. Ул Кытай юане пьедесталга менәр дип фаразлый, без кире кагабыз. Юань вакытлыча өстенлек алырга тырышыр, әлбәттә, бернидәр уңышларга да ирешер, әмма аның өстенлеге дә кыска гомерле булыр. Эш шунда: хәзерге вазгыятьтә бер генә илнең дә акчасы планетакүләм лидерлыкны үз кулына ала алмаячак. Долларның кояшы байый, башка бер генә валюта да кояш елмаймаячак.

Илләр, берләшеп, уртак валюта эзләргә тырыша үзе. БМО Генераль секретаре Антониу Гутерриш дөньяның финанс системасын радикаль рәвештә үзгәртеп корырга чакырып чаң суга, «Яңа Бреттон-Вудс вакыты җитте», – дигән фикер әйтә. Бреттон-Вудсның ни икәнен укучыларның күпчелеге аңламас, әлбәттә. Кыскача гына шәрехләп үтик. 1944 елда Америкадагы Бреттон-Вудс курортында халыкара конференция җыела һәм шунда долларны финанс тәхетенә күтәрәләр. Ул алтын белән тәэмин ителергә тиеш була, 35 долларны бер унция алтынга тигезлиләр. Соңыннан янкилар «Никсон шогы» дигән адымга барып, алтын стандарттан баш тарталар, әмма доллар халыкара акча ролен үтәп кала. Американнарга бик зур өстенлек бирә бу. Мәсәлән, үткән елда Американың сәүдә дефициты 948,1 миллиард долларга тиң булды, ягъни үзләре сатканга караганда шуның кадәр күбрәк товар сатып алдылар, чөнки бөтен дөнья өчен акчаны шулар баса. Кытайда тышкы сәүдә дефициты юк, 101 миллиард долларлык профицит бар. Россиядә дә сәүдә дефициты түгел, профицит. 2022 елның беренче тугыз аенда ук Россия читкә 431 миллиард долларлык товар саткан, 180 миллиард долларлык алган. Файдаланылмаган 251 миллиард доллар Россия өчен кәнфит кәгазе кебек кенә,

vk.com

стратегик чимал саттың һәм берни дә алмадың һәм алмаячаксың да дигәнне аңлата. Хәзер олигархлар да акчаларын долларда сакламый, Антальяда, я Дубайда күчемсез милек алырга тырышалар.

Эш сәүдә дефицитында яки профицитында да түгел. Американнар дистә еллар буе тышкы сәүдәне баланслый алмасалар да бөлмиләр, ә башка дәүләтләр бөлә, шуңа күрә артык товар сатып алудан сакланырга мәҗбүр булалар. Күз алдыгыза китерегез әле: Россия үзе саткан кадәр товар китертә алса, безнең базарларда нинди муллык булыр иде. Сумның курсы үсәр, товар бәяләре очсызланыр һәм башка бонуслар өскә калкып чыгар иде. Дефляция булмасын өчен, күпләп социаль ярдәм өләшергә туры килер иде. АКШ шулай итеп яши. Байденга студентлар алган кредитны кичерү өчен триллион доллардан артык акчаны өстәлгә чыгарып салу берни дә тормый, чөнки АКШ хөкүмәте түгел, студентлар әҗәтен бу очракта бөтендөнья халыклары бергәләшеп түли. Бөтен планетага бүлгәч, авыр тоелмый ул.

Бу вазгыять белән башка халыклар килешә алмый. Бары тик Американың гадәттән тыш хәрби куәте, сәяси басым ясау мөмкинлеге генә куркытып тора. Кем долларга каршы баш калкыта, шуңа санкцияләр игълан ителә һәм очкыч йөртүче хәрби кораблар төркеме аның ярларына юнәлә. Әйтик, ни өчен Төньяк Кореяга каршы американнар сугышмый, чөнки доллар моңа кадәр хәтта аларның эчке базарында да иркен кулланылды. Әмма риза булмаучылар саны үскәннән-үсә. Кагазь, хәтта Антониу Гутерриш яңа Бреттон Вудс таләп итә. Дәүләтләр төркемнәре үзләренә башка валюта эзли башлады. БРИКС илләре үз валюталарын кертү турында сөйләшүләр алып баралар. Россиянең финанс министры Силуанов андый валюта перспективасы турында «Беренче канал»дан сөйләде. Илләр үзара милли валюталарда сәүдә итешеп карыйлар, уңайсыз. Барлык илләрне дә канәгатьләндерерлек уртак валюта кирәк, моңа берәү дә шикләнми.

Гутерриш таләп иткән яңа Бреттон Вудс була аламы? «Ватаным Татарстан» хәбәрчесенең бу сорауга җавабы тискәре. Яңа валюта килешүе төзү өчен, Өченче Бөтендөнья сугышы һәм бер зур дәүләтнең башкаларның бугазлашуын читтән карап торуы һәм аларга корал сатып баюы кирәк. Башкалар җимерелеп-таралып беткәч, ул, кредитлар биреп, җиһазлар сатып, аларны үз канаты астына җыячак. Үткән гасырда Америка эшләгәнне эшләячәк ягъни, үз валютасын тагачак. Болай үзара килешеп кенә нинди дә булса кәгазь акчаны уртак валюта итеп кертү планнары тормышка ашмаячак. Бер дәүләтнең валютасын башкалар өчен дә акча итеп тота башласаң, «Триффин парадоксы» дигән нәрсә пәйда була. Бердән, акча башкаларга да җитсен өчен, аны күп итеп басарга туры киләчәк, икенчедән, валюта ышанычлы булсын өчен, эмитент илнең товарлары белән тәэмин ителгән күләмдә генә басу таләп ителә. Долларны менә шул парадокс җимерә дә инде.

Ышанычлы валютаның булмавы бик зур проблемалар китереп чыгара дөньяда. Бөтендөнья сугышын котылгысыз итә. Без шул сугышны төенли торган конфликтлар чорында яшибез. Бик кызганыч һәм аяныч: ул конфликтлар үсә, кискенләшә, үзләренә корбаннар сорый. Менә шундый катлаулы мәсьәлә ул акча-макча проблемасы. Бүген лидерлыкка дәгъва иткән һәм үз акчасын башкаларга валюта итеп тагарга омтылган державалар барысы да түнтәреләчәк, дөньякүләм бөтенләй башка көч калкып чыгачак һәм дилбегәне үз кулына алачак. Кәгазьләр акча булудан туктаячак. Без, бер дә курыкмый, шундый фараз ясыйбыз давыллы еллар алдыннан. Язма башындагы фаразларны карагыз әле, унҗиде ел элек әйтелгәннәр бүген безнең чынбарлыкка әйләнеп килә.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ДУС ИТМӘСЕН ШЕШӘ

Авылларда эчкечеләр саны арта! Белгечләр шулай дип чаң суга. Сәбәпләрен дә атыйлар. Берәүләр, салада эчкечелек тамыр җәюгә эшсезлек, халыкның очын очка ялгап яшәве этәргеч булды, дигән фикердә. Икенче берләре исә, төп сәбәп дип, ил-көндәге вакыйгалар, күңел тынычлыгы булмауны атый.

Курку дуслаштыра

Бер ел эчендә Россия авылларында эчкечелектән интегүчеләр саны 7 процентка арткан. Бу хакта Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының Иҗтимагый сәламәтлек һәм балаларга медицина ярдәме департаменты җитәкчесе Елена Шешко хәбәр иткән. Рәсми мәгълүматларга караганда, бүген Россиядә 1,2 миллион кеше хәмергә бәйлелектән интегә. Ел дәвамында теркәлгән үлем-китем очракларының да күбесе әнә шул афәт аркасында килеп чыккан. Әйтик, бавыр таркалу, миокард инфаркты, панкреатит аркасында вафат булучыларның күбесе – хәмер белән мавыккан кешеләр, ди белгечләр.

Республика наркология диспансерының баш табиб урынбасары Илдар Таҗетдинов сүзләренә караганда, Татарстанда конкрет авылларда эчкечелек күрсәткече буенча статистика алып барылмый. Республика күләмендә исә барлыгы 30 меңнән артык кеше эчкечелек буенча исәптә тора. Андыйлар саны ел саен 1–2 процентка арта бара, ди белгеч. Авыл җирендә хәмер белән дуслашучылар саны артуның исә берничә сәбәбен атый ул.

– Бу, беренче чиратта, халыкның мәшгульлегенә бәйле. Авылда эш булмау – элек-электән килгән проблема. Ил-көндәге вакыйгаларның да йогынтысы зур булды. Башта коронавирус белән сыналдык. Аннары өлешчә мобилизация башланды. Халык, ничә елдан бирле куркып, билгесезлектә яши. Күпләр шушы халәттән чыгу юлын хәмердә таба. Вакытлыча булса да онытылып торырга тели, – ди белгеч.

Илдар Таҗетдинов сүзләренә караганда, узган елның сентябрендә игълан ителгән өлешчә мобилизация халыкның күңел халәтенә аеруча тискәре йогынты ясаган.

– Мобилизацияләнүчеләрне безгә диагностикага алып килә башладылар. Күпләрнең хәмергә нәкъ менә шул курку, билгесезлек аркасында гына үрелгәнлеге ачыкланды. Аннары кешене гадәти тормышыннан аерып, ябык бинада, ниндидер кысада яшәү аның психикасына шулай ук тискәре йогынты ясады. Якыннары арасында да төшенкелеккә бирелүчеләр бихисап. Авылларда эчкечелек күрсәткече артуга менә шушы хәлләр дә сәбәпче булды, – ди ул.

Тынычлык җитми

Эчкечелек юлына баскан кешеләргә инде 40 елдан артык ярдәм итүче тәҗрибәле табиб-нарколог Рөстәм Вәлиуллин да шул фикердә.

– Соңгы арада дөньяда, илдә барган вакыйгалар күпләрнең тормышының астын өскә китерде, җәмгыятьтәге киеренкелекне арттырды. Кагыйдә буларак, стресс арткан җирдә исерткеч эчемлекләр дә күбрәк кулланыла. Мәсәлән, 1990 нчы елларда да бик каты эчәләр иде. Моңа, нигездә, тормыш дәрәҗәсенең түбәнлеге, эшсезлек сәбәпче булды. Бүгенге тотрыксыз тормыш, шул ук эшсезлек кабат теңкәгә тия. Кеше акча җиткерә алмый. Көн дә ишетелеп торган күңелсез хәбәрләр дә кешенең психофизиологик халәтенә тискәре йогынты ясый бит. Кеше, аз булса да онытылыр, киеренкелектән котылыр өчен, хәмергә үрелә, – ди табиб-нарколог.

Психотерапевт, «Яшәү территориясе» социаль инициативалар үзәге башлыгы Антон Миронов фикеренчә, шәһәрдә дә, авылда да эчкечеләр саны елдан-ел арта бара һәм моңа гаҗәпләнергә кирәкми. Белгеч сүзләренә караганда, соңгы арада аларга ярдәм сорап килүчеләр арасында наркоманнар да күбәеп киткән.

– Күреп торабыз: илдә – кризис. Шуңа хәзер мобилизация, чикләүләр өстәлде. Күпләрнең киләчәккә планнары җимерелде. Халыкның керемнәре кимеде. Кереме кимемәгәннәрнең чыгымнары артты. Тормыш кыйммәтләнде. Элек бер сум торган әйбер бүген 5 сум тора. Мондый негатив, тормыш авырлыгы кешене акрынлап баса. Шәһәр җирендә ул яктан барыбер җиңелрәк әле. Каядыр барып кайтырга, бераз онытылырга, күңел ачарга мөмкин. Авылда – үле тынлык. Шуңа кеше төшенкелеккә дә тизрәк бирешә. Күпләр андый чакта беренче эш итеп шешәгә үрелә. Өстәвенә хәзер хәмер сатылу вакытын да озайтып куйдылар. Һава торышына каршы көрәшеп булмаган кебек, эчкечелекне дә җиңәрлек түгел. Бар да, нигездә, илдәге вазгыятькә бәйле. Тормышлар җайланып, илләр тынычланып, социаль проблемалар кимесә, эчкечеләр саны да азаер иде, – ди белгеч.

Уразайга кирәкми

Кукмара районының Уразай авылы – хәмердән бөтенләй баш тарткан авылларның берсе. Биредә исерткеч эчемлекләр сатылмаганга инде ун елдан арткан. Авыл җирлеге башлыгы Илгиз Нәбиев фикеренчә, моңа гаҗәпләнәсе юк. «Безнең авыл мәчете – районда манарасы киселмичә калган өч мәчетнең берсе. Мәчеткә йөрүчеләр уртага салып сөйләшеп эшләнгән эш бу. Имамның да йогынтысы бик зур. Ул вакытта кибет хуҗасы да каршы килмәде. Аңа да рәхмәт», – ди ул.

Шулай да бу юнәлештә үзгәреш җилләре авылда Хәмзә хәзрәт Харрасов мулла итеп билгеләнгәч исә башлаган. Авылда эчкечелек сакланугa, кибетләрдә хәмер сатылуга эче поша аның. Кибеттә хәмер сатуны туктатып кына вазгыятьнең үзгәрмәячәген бик яхшы аңлый ул. Шуңа авыл халкы белән җыелышып сөйләшәләр.

– Авылларда эчкечелек артуга динсезлек сәбәпче. Әгәр кеше дин юлына баса икән, бу мәсьәлә үзеннән-үзе төшеп кала. Эчкечелек булган җирдә тавыш, кыйнаш була, күпме гомерләр өзелә. Бу мәсьәлә элек-электән борчый иде инде. Бозыклыкның, бөтен начарлыкның анасы – хәмер. Аннан котылу юлларын күптән эзли идек. Әмма монда, иң беренче чиратта, халыкның хәмерне кирәксенмәве, безнең тәкъдимне аңлап кабул итүе ярдәм итте. Кул күтәртеп, тавыш бирдереп, ул мәсьәләне хәл иттек. Бөтен кеше бертавыштан авылда хәмер сатылмауга ризалашты. Авыл халкы тарафыннан ихтыяҗ булмагач, кибетчеләр дә киштәләрдән хәмерне алып куярга мәҗбүр булды. Хәмер сатылмый башлагач, тормышта бәрәкәт артты. Бу һәрбер хуҗалыкта, авыл халкының тормыш-көнкүрешендә сизелә, – ди Хәмзә хәзрәт.

Күп тә үтми, уразайлылар керткән яңалык күршедәге Аш-Бүҗи авылында да тарала. Биредә инде дистә елдан артык хәмер сатылмый. Актаныш районының Кәзкәй авылында да соңгы өч елда хәмер сатылмый башлаган.

– Халык белән килешеп эшләнде бу. Алар арасында канәгатьсезлек белдерүче булмады. Хәмер булмагач, урамда арлыбирле ямьсезләнеп йөрүче дә, криминал да юк, җыелышып өйдә эчеп ятулар кузәтелми, гаиләдәге низаглар да азая, – ди җирлек башлыгы Камил Әхмәтгалиев.

Фикер

Эльмира МИАССАРОВА, клиник психолог:
– Үзәк нерв системасы аеруча сизгер булган кешеләр стресска тизрәк бирешә. Тормышта үз өстенә җаваплылык алырга күнекмәгән кеше дә бүгенге катлаулы вазгыятьтә бик тиз сына. Андыйлар арасында, кыенлыкларга түзә алмыйча, кыек юлга кереп китүчеләр, начар гадәтләргә, шул исәптән эчкечелеккә бирелүчеләр дә байтак. Бүгенге шартларда үз-үзеңне югалтмас, төшенкелеккә бирелмәс өчен, иң беренче чиратта, вазгыять үзгәрүенең бездән генә тормавын аңларга кирәк. Булдыра алган кадәр тынычлык сакларга тырышыгыз. Монда инде контраст душ, мунча керү, саф һавада йөрү кебек гади генә әйберләрдән башлап, якыннарың белән күрешү, кунакка йөрешү, яраткан эшең белән шөгыльләнү кебек бар нәрсә ярдәмгә киләчәк. Нәрсә генә эшләсәгез дә, гел хәрәкәттә булыгыз, кыскасы.

2022 ЕЛДА ТАТАРСТАНДА АЛКОГОЛЬ САТУ КҮЛӘМЕ (мең декалитр)

гыйнвар	481,5
февраль	425,0
март	463,3
апрель	435,2
май	472,4
июнь	474,7
июль	479,2
август	478,8
сентябрь	473,9
октябрь	489,1
ноябрь	479,2
декабрь	691,1
Барлыгы	**5843,4**

Дәүләт Алкоголь инспекциясе мәгълүматларына караганда, узган ел Татарстанда **5,84** млн декалитр исерткеч эчемлек сатылган. Бу, алдагы ел белән чагыштырганда, **4** процентка күбрәк. Сатылган аракы күләме барлык районнарда диярлек арткан. Шулай да иң югары күрсәткечләр – Кайбыч **(+24%)**, Югары Ослан **(+20%)**, Чүпрәле һәм Яңа Чишмә районнарында **(+20%)**.
Бүген Татарстанда бер кешегә 15 л хәмер туры килә. Бу яктан иң югары күрсәткечләр – Югары Ослан **(22,6 л)** һәм Лаеш **(19,4 л)** районнарында. Аксубай **(7,3 л)**, Чүпрәле **(8,2 л)**, Спас **(8,6 л)** һәм Тәтеш районнарында **(9,4 л)** бер кешегә иң аз күләмдә хәмер туры килә, ди белгечләр. Казанда әлеге күрсәткеч – **17,5 л**.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

МИЛЕКЧЕ ДӘ, ХИСАПЧЫ ДА

«СЧЕТ-ФАКТУРА»ДАГЫ САННАРДАН КУРКЫРКА КИРӘКМИ, ДИ БЕЛГЕЧЛӘР

Белгечләр коммуналь хезмәтләр өчен исәп-хисап ясаганда аңлырак булырга киңәш итә. Югыйсә, күрше белән очрашкач, ут һәм су өчен бәяләрдән зарланып алабыз да, беттекитте. Коммуналь түләүләрнең очына барыбер чыгып булмый, дип фикер йөртүчеләр дә җитәрлек. «Белмим»нең беләге авыртмыймы шунда. Күрсәтелмәгән коммуналь хезмәтләр өчен акчаны кире кайтарып буламы? «ВТ» хәбәрчесе шуны ачыкларга тырышты.



vk.com

Идәннәре… чүп кенә

Башыңа төшсә, башмакчы булырсың, ди халык мәкале. Ике ел чамасы элек Казанның Идел буе районында урнашкан фатирга күченгәч, күпкатлы йорттагы подъезд идәннәренең чисталыгына, дөресрәге, әлеге чисталыкның булмавына тәмам аптырадык. Ай саен коммуналь хезмәтләр, шул исәптән гомуми кулланыштагы урыннарны карап торганнары өчен (подъезд идәннәрен юу да шунда керә. – **Ред.**) акча түлибез югыйсә. Тора-бара эшнең җаен таптык: ТКХ өлкәсендә халыктан гаризалар кабул итүче «Ачык Казан» онлайн сайты аша айга бер тапкыр «сәлам хаты» юлыйбыз да, иртәгәсе көнне үк идәннәрне юып китәләр.

Узган ел ахырында намуссыз идарәче оешмага каршы көрәш алымын үзгәрттек. Декабрь буе юылмаган идәннәрне атна саен фотога төшереп бардым да, гыйнварда счет-фактура килгәч, идарәче оешма җитәкчесенә кабул итүгә язылдым. Ниятем – күрсәтелмәгән хезмәт өчен исәпләнгән акчаны кире кайтару. Баксаң, халыкка хезмәт күрсәтүче оешмага тиз генә эләгеп тә булмый икән. «Чиратка яздык. Ике атнадан соң килерсез», – диделәр телефоннан. Сүз уңаеннан, декабрь түләвендә гомуми кулланыштагы урыннарны тәртиптә тоткан өчен генә дә 2300 сум язганнар. Җитәкче янына барырга теләвемне бик тиз сизеп алдылар. Мин чират көткән арада без яшәгән йортка яңа идән юучыны эшкә алганнар. Идарәче оешма вәкиле кесә телефонына юылган идән фотоларын ук төшереп җибәрде. Эшли беләләр икән лә…

Үзебез битараф

– Ни кызганыч, көчемсез милек хуҗалары үз хокукларын белми, – ди «Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге» ассоциациясенең башкарма директоры Дмитрий Романов. – Ай саен килгән счет-фактураны түлиләр дә, шуның белән шул. Күпфатирлы йортларда яшәүчеләр, гомумән дә, җыелышларда катнашмый. Шуңа күрә мондый җыеннарның нәтиҗәсе дә юк. Көчемсез милек хуҗаларының 1–2 проценты гына үз хокукларын белеп эш итә.

Калганнар дәшми-тынмый гына яши дип фикер йөртү дөрес түгел анысы. Белгеч әйтүенчә, былтыр ул җитәкләгән иҗтимагый үзәккә генә дә коммуналь хуҗалыкка бәйле сораулар буенча 1800гә якын кеше мөрәҗәгать иткән. Аларның күбесе түләү кәгазьләрендәге бәяләргә бәйле.

– Алдагы еллардан аермалы буларак, былтыр тарифлар ил күләмендә бер ел эчендә ике тапкыр – июль һәм декабрьдә артты. Шуңа күрә коммуналь түләү кәгазьләре сизелерлек кыйммәтләнде. Халык та борчуга төште. Безгә мөрәҗәгать итүчеләрнең һәр икенчесен диярлек ут-су өчен исәпләүләр һәм тарифлар мәсьәләсе борчый. Күп очракта халык арасында аңлату эшләре җитми. Без бәйнә-бәйнә барысын да төшендереп бирергә тырышабыз. Көне-сәгате белән хәл итеп булмаган сораулар да бар, әлбәттә. Мәсәлән, капиталь ремонтка бәйле мөрәҗәгатьләрне ачыкларга вакыт кирәк. Бу мәсьәләдә идарәче оешмаларга, торак милекчеләре берләшмәләренә халык белән күбрәк эшләргә кирәк дип саныйм. Гап-гади мисал: подъездлардагы игълан тактасына тарифларга бәйле үзгәрешләрне язып элергә нәрсә комачау итә соң? Бу йортта фәлән елда капиталь ремонт булачак дип, алдан хәбәр итсәләр дә, төрле дәүләт оешмаларына шикаять язучылар саны бермә-бер кимер иде, – ди Дмитрий Романов.

Аның әйтүенчә, коммуналь хезмәтләр тиешенчә яки гомумән күрсәтелмәвенраслау өчен шактый бусага таптарга туры киләчәк. Моның өчен кулда дәлилләр булуы зарур. Акчаны фәкать милек хуҗасы гаризасы нигезендә генә кире исәпли алалар, дип тә искәртте ул.

– Еш кына кыш көне өйдә салкын дип зарланалар. Ә моны ничек дәлилләргә? Мәсәлән, күпкатлы йорттагы бөтен фатирларда җылы, ә берсендә температура 18 градустан да түбәнрәк икән, чыннан да, артык түләгән акчаны кире кайтарып бирергә тиешләр. Тикшерү нәтиҗәсендә бүлмәләрдә температура 18–20 градус чамасы булуы ачыкланса, ә бу шактый салкынча инде, монда бернинди канун бозу очрагы да юк. Әлеге күрсәткеч СанПиН нормаларына туры килә. Кыскасы, бу өлкәнең нечкәлекләре шактый, – ди иҗтимагый үзәк җитәкчесе.

Күрше йорт, күрше урамда яшәүчеләр белән чагыштырганда, безгә коммуналь хезмәтләр өчен акча исәпләгәндә «шыттыралар» дип фикер йөртүчеләрне дә тынычландырды ул. Бүген коммуналь түләү кәгазьләренең барысы да диярлек «Татэнергосбыт»ның Бердәм исәп-хисап үзәкләре аша уза. Биредә бөтен эш үзәкләштерелгән. Милек хуҗасы исәпләгеч күрсәткечләрен язып җибәрә дә, аңа гамәлдәге тарифлар нигезендә түләү язалар. Күпме су агызсаң, шулкадәр түлисе, кыскасы.

Кемнәр түләми?

Татарстан Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгы мәгълүматларына караганда, кулланучы биш көн һәм аннан да күбрәк өйдә булмаган очракта, коммуналь түләүләр өчен акчаны яңадан исәпләтә ала. Тик шунысы бар: бу – техник мөмкинлекләр булмау аркасында, торак бинага исәпләгечләр куйдыра алмаган милек хуҗаларына гына кагыла. Исәпләгечләр ватылу ут һәм су өчен акчаны кире кайтаруга сәбәп була алмый. Шулай ук, йортны карап тору өчен кирәкле гомуми хезмәтләр өчен дә барыбер түләргә туры киләчәк. Исәп-хисап гаризаны кабул итеп алганнан соң, биш эш көнендә ясала.

Вакытлыча өйдә булмаганны раслап та күрсәтергә туры киләчәк. Мәсәлән, туганнарга яки эш буенча икенче шәһәргә китүчеләр гаризага юл билетын беркетә ала. Белгечләр өйдә исәпләгечләр урнаштыру өчен техник мөмкинлекләр булмавын дәлилләүче документларны да сорап алырга мөмкин. Исәп-хисап күп дигәндә алты айга ясала. Аннары гаризаны яңадан язарга туры киләчәк.

Каты көнкүреш калдыкларын чыгарган өчен исәп-хисап белән дә шул ук хәл. Ялга китү, хастаханәдә яту кебек сәбәпләр аркасында, вакытлыча өйдә булмаганны дәлилләп күрсәтә аласыз икән, чүп өчен түлисе дә юк. Бу мәсьәләдә 1 марттан яңалык та гамәлгә керәчәк. Эш шунда ки, илдә әлеге төр түләүнең тәртибе аерыла. Кайбер төбәкләрдә, шул исәптән Татарстанда аны фатирда яки йортта яшәүчеләр санныннан чыгып исәплиләр. Ә кайдадыр ул квадрат метр исәбеннән алына. Соңгыларына моңарчы чүп түкмәсәләр дә, акча кайтарылмады. Быелның языннан бу мәсьәләдә һәркем тигез хокуклы булачак. Гаризаны идарәче оешмага яки каты көнкүреш калдыклары операторы белән турыдан-туры килешү булган очракта, чүп чыгаручыларга язарга кирәк. Милек хуҗалары чүп өчен түләүдән тулысынча азат ителми, дип тә кисәтә белгечләр. Сүз уңаеннан, Татарстанда каты көнкүреш калдыкларын чыгарган өчен күпфатирлы йортларда яшәүчеләр – җан башыннан 103 сум 93 тиен, шәхси йорт хуҗалары кеше саен 112 сум 74 тиен акча түли.

Бәясенә күрә сыйфаты

Билгеле булганча, коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр әле күптән түгел, узган елның 1 декабрендә артты. Республика күләмендә әлеге күрсәткеч уртача 9 процент тәшкил итте. Моннан ары коммуналь хезмәтләр 2024 елның җәендә генә кыйммәтләнәчәк. Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Александр Груничев әйтүенчә, халыкка күрсәтелгән хезмәтләрнең бәясе аның сыйфатына туры килергә дә тиеш.

> Мәсәлән, Бөгелмәдә яшәүчеләр өйдәге торбаларның бер караганда – җылы, икенче караганда суык булуыннан күпләп зарланды. Моңа бәйле кыенлыклар булуын җылылык белән тәэмин итүче оешма да раслады. Тик менә коммуналь хезмәтләр өчен түләү кәгазендә бу берничек тә чагылыш тапмаган. Әлеге мәсьәлә контрольгә алынды. Халыкка килмәгән җылылык өчен акчаны кире кайтарачаклар.

Ул тагын бер кат искәртте: коммуналь хезмәтләрнең сыйфаты, аларның вакытында күрсәтелмәве яки исәпләүләргә бәйле шикаятьләр булган очракта, иң элек коммуналь хезмәтләрне күрсәтүчегә, ә алардан тиешле җавап булмаса яки ул канәгатьләндермәсә, Татарстан тарифлар буенча дәүләт комитетына яки Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Әлеге мәсьәләне Татарстан Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгында да көн кадагында тоталар. Аннан алынган мәгълүматларга караганда, былтыр халыктан барлыгы 4337 гариза килеп ирешкән. Шуның яртысы диярлек коммуналь хуҗалык өлкәсенә карый. Барыннан да бигрәк, торак фонды һәм йорт тирәсен тиешенчә карап торуга бәйле мөрәҗәгатьләр күбрәк. Икенче урында – коммуналь хезмәтләрне тиешенчә күрсәтмәү. Халыкны күпфатирлы йортлардагы капиталь ремонт мәсьәләсе дә борчый. Алдагы ел белән чагыштырганда, халыктан килеп ирешкән мөрәҗәгатьләр саны 4 процентка кимүен дә әйткәннәр. Бәлки, аңлырак була башлаганбыздыр.

…Сүзне подъезд идәннәреннән башлаган идек бит. Эшне аңлатып, фотоларны да күрсәткәч, идарәче оешма җитәкчесе коммуналь хезмәтләрнең, чыннан да, тиешенчә күрсәтелмәвен раслады. Димәк, пычрак идәннәр өчен түлисе булмаган. Акчаны кире кайтарырга вәгъдә иттеләр. Менә шундый сабак!

Белеп торыгыз!

Татарстан Тарифлар буена дәүләт комитеты хәбәреннән:
– Халыкка ярдәм итү максатыннан, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә ташлама-субсидияләр бирү каралган. Мондый ярдәмгә коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары гомуми айлык керемнәренең 21 процентыннан артып киткән гаиләләр өмет итә ала. Субсидия рәсмиләштерү өчен яшәү урыны буенча социаль яклау бүлекчәләренә мөрәҗәгать итәргә яки дәүләт порталы аша гариза җибәрергә кирәк. Ул ярты елга билгеләнә, аннары яңадан документлар тапшырасы булачак. Акчалата ярдәмгә муниципаль яки дәүләт торагында яшәүчеләр, наем килешүе нигезендә фатир алып торучылар, торак кооперативы әгъзалары, фатир, шәхси йорт хуҗалары дәгъва кыла ала. Тагын бер шарт – торакның мәйданы. Ул билгеләнгән стандартларга туры килергә тиеш. Әлеге күрсәткечне һәр төбәк үзе билгели. Татарстанда ул бер кешегә – 40 квадрат метр, ике кешелек гаиләдә җан башына – 23 квадрат метр, өч кешелек гаиләдә исә 17 квадрат метр тәшкил итә. Истә тотыгыз: коммуналь түләүләр буенча бурычлары булганнарга субсидия бирелми.

ҖИР ЯРАСЫ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Яшәү өчен көрәш

Евгения Корбанова Аланиядә яши. Җир тетрәгән көнне инде беркайчан да хәтереннән җуя алмас бугай ул. «Шулкадәр куркыныч иде. Өйдәге бөтен нәрсә урыныннан күчте. Кешеләр жәл. Урамга йөгереп чыгуга, таныш-белешләрне барладык. Без белгәннәр барысы да сау иде. 1–1,5 атна чамасы элек җир тетрәү булган иде инде. Әмма әллә нинди куркыныч күрмәдек. Ул чакта ишекләр, пәрдәләр тибрәнеп алды да бетте. Без гаиләбез белән сигезенче катта яшибез. Төркиядә күпме яшәп, җир тетрәвен беренче тапкыр чын-чынлап тойдык», – дип сөйләде ул.

Кирилл исемле әңгәмәдәшебез Мәрсин провинциясендә яши. Аның да 6 февраль иртәсе хәерле булмый.

– Иртәнге сәгатьләрдә караватт шыгырдаган тавышка һәм аның урыныннан күчүен аңлап уяндык. Аннан кисәк кенә диварлар, идән селкенә башлады. Без 10 нчы катта яшибез! Моңа кадәр җир тетрәү очракларына юлыккан булмады, шундук вазгыятьнең җитди булуын чамаладык. Тиз-тиз генә җыендык та урамга чыгып киттек. Машинабыз бар. Урамга чыккач, үзебез белән балалы бер гаиләне алдык та шәһәрдән читкәрәк юл тоттык, – дип сөйләде ул. – Без Эрдәмли шәһәрендәге халыкны кабул итү пунктында тукталдык. Монда килгән һәр кешегә урын табылды. Ипи, чәй, кайнар аш бирделәр.

Гыйнвар аенда Татарстаннан Төркиягә иҗади командировкага киткән фотограф Венера (якыннарын борчуга салмас өчен, исеме үзгәртелде. – **Авт.**) да Газиантәп шәһәрендә җир тетрәү шаһиты була. «Әлбәттә, халык куркуда иде. Ягулык станцияләрендәге кибетләрне генә алыйк: нәрсә бар, бөтенесен кырып диярлек сатып алып бетерделәр. Интернетта әллә ни утырып та булмады, дөресен әйткәндә, системага авырлык китермәсен өчен, хакимият интернеттан файдалануны киметергә кушкан иде. Газиантәптән Бурсага, Бурсадан Истамбулга автобус белән кайттым. Бер тәүлек буе авызга ризык капмаган, йокы күрмәгән килеш йөрелде. Туган якка кайту белән психологка язылаcы булыр. Газиантәптә әле дә җир тетрәүләр булып тора. Азык-төлек, газ, су запаслары да кими... Җылы да юк...» – дип, тәэсирләре белән уртаклашты ул.

Тумышы белән Екатеринбургтан булган Сергей Төркиядәге вазгыять белән үзенең «Телеграм»дагы сәхифәсендә уртаклаша. Егет коткы таратып утырмый, киресенчә, көчне бер учка җыеп, булышырга тырыша. Мәсәлән, кан бирү, гуманитар ярдәм җыю пунктларының адресларын урнаштыра, кайда нинди ярдәм кирәк – белешә.

– Вазгыятьне һава торышы да боза бит әле. Гыйнварда ул 15 градус тирәсе җылы иде. Шушы көннәрдә карлы яңгыр ява башлады. Җил, яңгыр, суык. Мондый шартларда кешеләрне җимерекләр астыннан эзләү, чыгару тагын да кыенлаша. Андагы йортларның диварлары тотрыксыз, – ди ул. – Администрация биналары, кунакханә, мәктәп ише биналарда кешеләрне урнаштырырга тырышалар. Ир-атлар коткаручыларга ярдәм итә. Гуманитар ярдәмне әледән-әле китереп торалар. Әлегә фаҗигането ни дәрәҗәдә коточкыч зыян салганын чамалап, бәяләп бетерү дә кыен.

Уртак бәла

Ил төкерсә, күл була. Бу фаҗига (куркыныч нәтиҗәләр бәрабәренә, билгеле) кешелекнең иң күркәм сыйфатын – мәрхәмәтне уята алды. Булышырга өндәүне дә көтеп тормыйча, дөньяның төрле почмакларында яшәүче кешеләр зыян күргән дәүләтләргә матди, рухи ярдәм ирештерергә тотынды.

Татарстанда исә бу эш республика җитәкчелеге дәрәҗәсендә хупланды. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановнов Төркиядәге җир тетрәүдә зыян күрүчеләргә гуманитар ярдәм җыюны оештырырга кушты. Оештыру эшләре өчен вице-премьер Ләйлә Фазлыеваны җаваплы итеп билгеләделәр. Республикада акчалата ярдәм күрсәтергә теләүчеләр өчен махсус банк счеты да ачылды.

Төрек кардәшләребезгә кайгы уртаклашу сүзләрен Дәүләт Советы депутатлары да юллады. Альберт Хәбибуллин, Ринат Гайзатуллин, Римма Ратникова, консуллыкта булып, депутатлар исеменнән кайгы уртаклашу китабында теләкләр калдырды. Моннан тыш депутатлар ил халкының Төркиягә һәрьяклап ярдәм күрсәтергә әзер булуларын әйтте.

– Безнең халыклар тарихи яктан бәйләнгән. Мондый фаҗигале көннәрдә тугандаш мөнәсәбәтләребез аеруча нык чагыла, – диде Альберт Хәбибуллин.

Римма Ратникова исә республикада Төркиягә ярдәм итү йөзеннән кирәк-яраклар җыю пунктлары ачылуын әйтте. «Табигый бәла-казалардан берәү дә якланмаган. Шуңа күрә дә бер-беребезгә авыр чакта ярдәм итү – намус эшебез», – диде депутат.

Халык күңеле дә киң. Инглиз теле буенча репетитор Сабина Исхакова, әлеге фаҗига турында белүгә, консуллыкка илтеп тапшыру өчен кирәк-яраклар җыя башлый. Аңа дус-ишләре дә кушыла.

– Җылы киемнәр, юрганнар кирәк. Мин консуллыкка иртән үк килдем. Бу сәгатьләрдә үк кеше күп иде инде. Барысы да кирәк-яраклар тапшыра. Без дә үз өлешебезне керттек. Үз авырлыгым кадәр кирәк-яраклар тапшырдык. Бу бәла бөтен кешене берләштерде. Таксистлар да ярдәм итә хәтта, – диде ул.

Төркиягә кыш чыгарга күченгән татар блогеры Резеда Миңнегулова зыян күрүчеләргә кичекмәстән ярдәм итүгә ире белән бергә алынган. Бернича көн рәттән кирәк-яраклар сатып алу, аларны махсус пунктларга илтү белән мәшгульләр. Резедага Татарстандагы язылучылары да акчалата булыша.

– Дөньяда мәрхәмәтле кешеләр күп. Бу вазгыять әнә шуны ачыкларга ярдәм итте. Без бер сумманы бетереп өлгермибез, шундук яңа сумма җыела, – ди Резеда. – Төркиядәге кайбер танышларыбыз кешеләрне хәрабәләр астыннан табу, эзләү эшендә дә катнаша. Мәш килеп, генераторлар эзлибез менә. Берне булса да тапсак, күпме кешеләргә ярдәм итә алабыз бит! Димәк, җылылык та, кайнар ризык та, яктылык та булачак! Күңелгә тигәне – ятим калган балалар күп... Телевизордан җирле каналларны карарлык түгел. Күңел елый.

Исмәт ЭРИКАН, Төркиянең Казандагы Генераль консулы:

Милләттәшләребез олы кайгы кичерә. Аллаһы Тәгаләдән һәлак булучылар саны артмасын дип сорыйбыз. Бу сынауны кичерергә ярдәм итсен! Россиядәге Төркиянең өч консуллыгы ярдәм җыю эшен башлады. Беренче чиратта җылы кием, җылыткычлар, чатырлар, юрган кирәк. Төрек авиакомпанияләре аларны зыян күргән урыннарга бушлай илтеп тапшырырга әзер. Гуманитар ярдәмне җыю эше ял көннәрендә дә дәвам итәчәк. Без Татарстан җитәкчелеге һәм республика халкының безнең белән бергә булуын сизәбез. Аларга ихлас рәхмәтебез! Дипломатик вәкиллекләребез булган һәм булмаган шәһәрләрдә дә ярдәм күрсәтү компанияләре бар.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Башкаладагы консуллык Горький урамы, 23/27 йорт адресы буенча урнашкан.
Акчалата ярдәм итү өчен исәп-хисап счеты:
Благотворительный фонд "АК БАРС СОЗИДАНИЕ"
ОГРН 1061600052425
ИНН/КПП 1658079690/165701001
р/с 40703810100020000999 в ПАО "АК БАРС" БАНК
БИК 049205805
К/с 30101810000000000805
Назначение платежа: Помощь жителям Турции

REUTERS.com

Сан

Язма әзерләнгән вакытта алынган мәгълүматларга карасак, Төркиядәге фаҗигадә һәлак булганнарның саны **12** меңнән артты. Зыян күрүчеләр саны исә **60** меңнән узды. Сүриядәге афәттә **2992** кеше һәлак булган. Куркыныч саннар, ни кызганыч, көннән-көн үзгәрә... Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, Төркия һәм Сүриядә барлыгы **23** миллион кеше (шул исәптән **14** миллион бала) һәлакәтләр зонасына эләккән.

13 февраль | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АЛМАШ» 16+
10.00, 23.00 «ТРИ ТОВАРИЩА» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять»16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ» 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45, 05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 16+
19.00, 00.40 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
23.50 «Соотечественники» 16+
00.15 «Каравай». Народный вокал 6+
01.05 «Ком сәгате» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитры) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитры) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» Телевизион нәфис фильм 16+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитры) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.00, 22.05, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитры) 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитры) 16+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Евгений Миронов, Александр Робак, Вадим Ильин. «ПРОБУЖДЕНИЕ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?». Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Александр Горбатов, Юлия Снигирь, Мария Смольникова, Фёдор Лавров, Ян Цапник, Александр Яценко, Фёдор Добронравов, Ирина Пегова, Катерина Шпица, Борис Каморзин, Владимир Юматов, Олег Алмазов, Иван Агапов, Роман Мадянов, Сергей Селин и Александр Яцко. «ШАЛЯПИН» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ» 12+
03.45 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 Лыжный спорт. Фристайл. Акробатика. «Кубок чемпионов». Трансляция из Ярославля 0+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 15.20, 22.35 Новости
07.05, 18.45, 21.45, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00, 04.50 Специальный репортаж 12+
10.25 Профессиональный бокс. Александр Поветкин против Майка Переса. Трансляция из Москвы 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «География спорта. Самара» 12+
13.50 «Магия большого спорта» 12+
14.25, 04.00 Мировой футбол. Обзор 0+
15.25 «Громко» Прямой эфир
16.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Барыс» (Астана) – СКА (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
19.25 Хоккей. OLIMPBET. Чемпионат МХЛ. МХК «Спартак» (Москва) – «СКА-1946» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция.
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Сампдория» – «Интер». Прямая трансляция
01.30 Конный спорт. «Dubai World Cup Carnival». Трансляция из ОАЭ 0+
02.25 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – «Лада» (Тольятти) 0+
03.55 Новости 0+
05.05 «Громко» 12+

НТВ
04.50 Дарья Екамасова, Екатерина Гусева, Кирилл Плетнев. «А.Л.Ж.И.Р.» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Вадим Колганов, Анна Казючиц, Сергей Селин. «ДЕЛЬТА» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Никита Панфилов в детективе «АКУШЕР» (S) 16+
22.00 «МЕЛЬНИК» (S) 16+
00.00 Детектив «НЕВСКИЙ. ПРОВЕРКА НА ПРОЧНОСТЬ» (S) 16+
04.15 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30, 04.20 «6 кадров» 16+
06.40, 05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.35 «Давай разведёмся!» 16+
09.35 «Тест на отцовство» 16+
11.40 «Понять. Простить» 16+
12.40 «Порча». «Мост» 16+
13.10, 00.15 «Знахарка» 16+
13.45, 00.45 «Верну любимого» 16+
14.20 «Голоса ушедших душ» 16+
14.55 «ЧУЖИЕ И БЛИЗКИЕ» 16+
19.00 «МАЛЕНЬКАЯ ТАЙНА, БОЛЬШАЯ ЛОЖЬ» 16+
23.05 «Голоса ушедших душ» 16+
23.40 «Порча» 16+
01.15 «ЦЕНА ПРОШЛОГО» 16+
04.35 «Понять. Простить» 16+

ЗВЕЗДА
04.40 «ИЗ ПЛАМЯ И СВЕТА...». 3-я – 5-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.15 «БИТВА ЗА МОСКВУ». «АГРЕССИЯ». 1-я серия 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
13.45, 15.05 «ОПЕРАТИВНЫЙ ПСЕВДОНИМ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Миссия в Афганистане. Первая схватка с терроризмом». Документальный сериал. «Мармоль, 1984 год» 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Газовые войны» 12+
22.55 «Между тем» 12+
23.20 «БЕРЕГИСЬ АВТОМОБИЛЯ» 12+
02.40 «Загадки цивилизации. Русская версия». Документальный сериал 12+
03.25 «Хроника Победы». Документальный сериал 16+
03.50 «ОПЕРАТИВНЫЙ ПСЕВДОНИМ» 1-я и 2-я серии 16+

14 февраль | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 15.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АЛМАШ» 16+
10.00, 23.00 «ТРИ ТОВАРИЩА» 16+
11.00, 16.30 «Татарлар» 12+
11.30, 22.10 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ» 12+
12.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Адмирал» – «Ак барс». Прямая трансляция 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тәймә» 0+
16.00 «Туган җир» 12+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 16+
23.50 «Видеоспорт» 16+
00.15 «Соотечественники». Хотите, я вам почитаю... В. Качалов 16+
00.40 «Каравай». Сказки о золотых яблоках 6+
01.05 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитры) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитры) 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» Телевизион нәфис фильм 16+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитры) 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.05, 22.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
23.05 «Җырлыйк әле!» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитры) 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитры) 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Многосерийный фильм «ПРОБУЖДЕНИЕ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?». Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Александр Горбатов, Юлия Снигирь, Мария Смольникова, Фёдор Лавров, Ян Цапник, Александр Яценко, Фёдор Добронравов, Ирина Пегова, Катерина Шпица, Борис Каморзин, Владимир Юматов, Олег Алмазов, Иван Агапов, Роман Мадянов, Сергей Селин, Александр Яцко. «ШАЛЯПИН» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
00.10 Премьера. «Сергей Миронов. Свободная трибуна». Фильм Евгения Рожкова 12+
00.55 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.30 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ» 12+
04.10 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 Лыжный спорт. Фристайл. Акробатика. «Кубок чемпионов». Трансляция из Ярославля 0+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20 Новости
07.05, 14.25, 18.10, 21.30, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Профессиональный бокс. PRAVDA FC. Дмитрий Кудряшов против Вагаба Вагабова. Трансляция из Москвы 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «Ты в бане!» 12+
13.50 «Магия большого спорта» 12+
15.50 «История Хуана Мануэля Фанхио». Документальный фильм 12+
18.30 Фигурное катание. Фестиваль «Влюблённые в фигурное катание». Прямая трансляция из Москвы
22.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. ПСЖ (Франция) – «Бавария» (Германия). Прямая трансляция
01.55 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Милан» (Италия) – «Тоттенхэм» (Англия) 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Пари НН» (Нижний Новгород) – «Зенит» (Санкт-Петербург) 0+

НТВ
04.45 Сериал «А.Л.Ж.И.Р.» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ДЕЛЬТА» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Детектив «АКУШЕР» (S) 16+
22.00, 00.00 Остросюжетный сериал «МЕЛЬНИК» (S) 16+
00.10 Детектив «НЕВСКИЙ. ПРОВЕРКА НА ПРОЧНОСТЬ» (S) 16+
04.20 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30, 05.05 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.15 «Давай разведёмся!» 16+
09.15 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.15 «Порча». «Змеевик» 16+
12.45, 00.05 «Знахарка» 16+
13.20, 00.35 «Верну любимого» 16+
13.55 «Голоса ушедших душ» 16+
14.30 Скажи, подруга 16+
14.45 «ЛОВУШКА ВРЕМЕНИ» 16+
19.00 «ИДУ ЗА ТОБОЙ» 16+
23.00 «Голоса ушедших душ» 16+
23.30 «Порча» 16+
01.05 «НЕ МОГУ СКАЗАТЬ «ПРОЩАЙ» 16+
02.30 «ОДНОКЛАССНИЦЫ» 16+
04.10 «6 кадров» 16+
04.15 «Понять. Простить» 16+

ЗВЕЗДА
05.20 «ОПЕРАТИВНЫЙ ПСЕВДОНИМ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.05 «БИТВА ЗА МОСКВУ». «АГРЕССИЯ». 2-я серия 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20 «Москва – фронту». Документальный сериал 16+
13.45, 15.05 «ОПЕРАТИВНЫЙ ПСЕВДОНИМ». 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Миссия в Афганистане. Первая схватка с терроризмом». Документальный сериал. «Нангархар, 1980 год» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ЖАРКОЕ ЛЕТО В КАБУЛЕ» 16+
02.35 «Загадки цивилизации. Русская версия». Документальный сериал 12+
03.25 «Хроника Победы». Документальный сериал 16+
03.50 «ОПЕРАТИВНЫЙ ПСЕВДОНИМ». 5-я и 6-я серии 16+

60 нчы ТУРНИР
17–18 ФЕВРАЛЬ, КАЗАННЫҢ «АК БАРС» КӨРӘШ САРАЕ

Татарстан Көрәш федерациясе | МИНСПОРТ Татарстан Спорт министрлыгы | «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе

АЧЫЛУ ТАНТАНАСЫ 17 ФЕВРАЛЬ КӨННЕ ИРТӘНГЕ СӘГАТЬ 10га БИЛГЕЛӘНГӘН

реклама 6+

КАЙСЫ РАЙОН НИЧӘ ТАПКЫР?

ГАЗЕТАБЫЗ БӘЙГЕСЕНДӘ БАЛТАЧ ЕГЕТЛӘРЕ 13 МӘРТӘБӘ ҖИҢҮ ЯУЛАДЫ

ЕЛ	КУБОК ИЯСЕ	ЕЛ	КУБОК ИЯСЕ	ЕЛ	КУБОК ИЯСЕ
1964	Сарман	1984	Балтач	2004	Киров (Казан)
1965	Буа	1985	Мамадыш	2005	Балтач
1966	Чистай	1986	Мамадыш	2006	Мәскәү (Казан)
1967	Актаныш	1987	Чаллы	2007	Чаллы
1968	Актаныш	1988	Балтач	2008	Вахитов (Казан)
1969	Тукай	1989	Балтач	2009	Чаллы
1970	Саба	1990	Чаллы	2010	Чаллы
1971	Тукай	1991	Балтач	2011	Әлмәт
1972	Түбән Кама	1992	Чаллы	2012	Әлмәт
1973	Түбән Кама	1993	Теләче	2013	Әлмәт
1974	Түбән Кама	1994	Питрәч	2014	Әлмәт
1975	Түбән Кама	1995	Чаллы	2015	Әлмәт
1976	Түбән Кама	1996	Кукмара	2016	Зәй
1977	Балтач	1997	Зәй	2017	Зәй
1978	Яшел Үзән	1998	Чаллы	2018	Зәй
1979	Арча	1999	Чаллы	2019	Теләче
1980	Балтач	2000	Балтач	2020	Теләче
1981	Балтач	2001	Әлмәт	2021	Әлмәт
1982	Балтач	2002	Балтач	2022	Әлмәт
1983	Балтач	2003	Балтач	2023	?

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

ҮПКӘ ДОШМАНЫ

Үпкә авырулары, аерым алганда пневмония, үлем-китемгә китергән чирләр рәтендә алдынгы урында тора. Коронавирус та иң беренче чиратта үпкәгә бәрде. Әлеге чир белән авырып терелүчеләр арасында үпкә ялкынсыну очраклары аеруча еш очрый. Аннан ничек сакланырга? Пневмония бернинди билгеләрсез генә уза аламы?

Әлмәт үзәк район хастаханәсенең табиб-пульмонологы Рөстәм НАСРЕТДИНОВ сорауларга ачыклык кертте.

:: Бүген хастаханәләрдә үпкә ялкынсынуга бәйле вазгыять ничегрәк?

– Узган елгыдан әллә ни аерылмый. Саннар артмый. Әмма соңгы арада пневмония күбрәк грипп, коронавирус кебек вируслы авырулардан соң өзлегү рәвешендә күзәтелә. Хәзер кеше рентген урынына күбрәк томография ясатырга тырыша. Ник дигәндә, ул икеләтә сизгер. Шуңа күрә соңгы арада вируслы пневмония очраклары күбрәк ачыклана башлады.

:: Коронавирус сәбәпле килеп чыккан пневмония башка вируслы авырулар, әйтик, шул ук грипп сәбәпле пәйда булганыннан аерыламы?

– Грипп белән коронавирус вакытында үпкәләр бер үк дәрәҗәдә зарарлана. Һәр ике очракта да альвеолалардагы кан тамырларына зыян килә. Әмма коронавирус вакытында алар күбрәк зарарлана. Шулай да хәзер инде халыкның әлеге чиргә карата иммунитеты бар. Шуңа күрә коронавирусны да бүген күпләр җиңелчә формада уздыра. Ковид вакытында үпкәләргә зыян килеп, аны авыр формада уздыру очраклары соңгы арада ун тапкыр диярлек кимеде.

:: Пневмония бернинди билгеләрсез дә уза аламы?

– Әйе, кызганыч ки, уза ала. Кешенең хәтта температурасы да күтәрелмәскә мөмкин. Пневмонияне нинди билгеләр буенча чамаларга соң? Андый чакта кешедә ютәл пәйда була. Ул көннән-көн көчәя. Кешедә хәлсезлек күзәтелә, тыны кысыла. Кандагы кислород дәрәҗәсе (сатурация) төшеп, кешенең тыны кысыла башласа, кичекмәстән компьютер томографиясе ясатырга кирәк.

:: Үпкә ялкынсынудан саклану өчен, нинди кагыйдәләрне истә тотарга киңәш итәсез?

– Грипп, коронавирус кебек вируслы чирләр аркасында пневмония барлыкка килмәсен өчен, иң беренче чиратта алдан хәстәрен күреп, вакцина ясатырга кирәк. Гриппка каршы вакцинаны сентябрь, октябрьдә үк ясатып кую хәерле.

vk.com

Дөрес, алдан өлгермәсәң, аны грипп котырган чорда кадатсаң да була. Коронавируска каршы вакцинаны ел дәвамында ясатырга мөмкин. Болар бар да чирне җиңелчә формада уздырып, пневмония кебек җитди өзлегүләрне булдырмый калырга ярдәм итә.

:: «Пневмо 23» вакцинасы кемнәргә тиеш? Аны бушлай ясатып буламы?

– Әлеге вакцина пневмония, отит, менингит кебек чирләр китереп чыгаручы пневмококка каршы ясала. Пневмонияне булдырмас өчен, аны биш елга бер тапкыр кадыйлар. Аны «Превенар 13» вакцинасы белән бергә ясату да яхшы. Прививкалар календаре буенча әлеге вакцина 2–3 айлык, 5–6 айлык, 1,5 яшьлек балаларга да билгеләнә. Шулай да «Пневмо 23» вакцинасы иң беренче чиратта хәвеф төркеменә кергән, 65 яшьтән өлкәнрәк, хроник үпкә авырулары, шикәр чире, йөрәк, аутоиммун авырулары булган, гемодиализдагы, яман шеш диагнозы куелган кешеләргә ясала. Әмма ул фәкать табиб белән киңәшеп кенә эшләнергә тиеш. Әлеге вакцинаны бушлай да ясатып була.

Тәмле дәва

Кечкенә дә төш кенә

Кытай галимнәре чикләвек куллануның йөрәк-кан тамырлары авырулары барлыкка килү куркынычын киметә алуын ачыклаган.

1 **Бадәм (миндаль).** Табиблар йөрәк авырулары белән чирләүчеләргә атнасына кимендә 60 грамм бадәм ашарга киңәш итә. Ул фосфор, калий һәм тимергә бай. Сатып алган вакытта бадәмнең эресен сайлагыз.

2 **Кешью.** Бу чикләвек иммунитетны ныгыта, йөрәк эшчәнлеген яхшырта һәм хәтта теш сызлауны баса. Көнгә барлыгы 20 кешью ашасагыз, сезнең организмга бер тәүлеккә җитәрлек тимер керәчәк. Чикләвекне кулланыр алдыннан, тәмле булсын өчен, кыздырырга кирәк.

3 **Пестә (фисташка)** аз калорияле һәм минераллар, витаминнарга бай, әмма алар белән аеруча мавыгырга кирәкми. Өлкән кеше өчен тәүлеклек норма – нибары 15 чикләвек. Ашкайнату тракты, сулыш юллары, азканлылыкны дәвалауда ярдәм итә, авырлы хатын-кызларның токсикозы булганда кулланалар, ир-атларның репродуктив сәләтен арттыра, йокысызлыктан булыша.

4 **Урман чикләвеге (фундук)** А һәм Е витаминнарына бай, ул баш мие эшчәнлеген яхшырта. Иң яхшысы – аны кыздырмый куллану.

5 **Әстерхан чикләвеге** азканлылыктан, нерв системасы, йөрәк һәм ашказаны авыруларыннан ярдәм итә. Даими куллану ир-атларны җенси көчсезлектән саклый.

6 **Эрбет (кедр) чикләвеге** витаминнар, макро- һәм микроэлементларга бай булуы белән аерылып тора.

Бигрәк тә балаларга һәм өлкәннәргә файдалы. Симез кешеләргә кедр чикләвеге куллануны чикләргә кирәк.

7 **Бразилия чикләвеге.** Көненә 2 чикләвек ашасагыз, организмыгыз тәүлеклек селен нормасын алачак. Аның җитмәве вакытыннан алда картаюга китерә. Моннан тыш, чикләвек сезгә дәрт һәм энергия, матур, чиста тире бүләк итәчәк һәм йөрәк, онкология авыруларының куркынычын киметәчәк.

8 **Кокос.** Җирдә иң зур чикләвекләрнең берсе – кокос. Бер чикләвекнең авырлыгы дүрт килограммга җитәргә мөмкин. Кокос тәмле генә түгел, файдалы да, анда В төркеме витаминнары, макро- һәм микроэлементлар күп. Иммунитетка, күрү сәләтенә, ашкайнату системасына, калкансыман бизнең эшләвенә яхшы йогынты ясый. Кокос сөте яшәртә.

Киңәш

Ютәл борчыса...

Ютәл вакытында, табиб билгеләгән дәвалау чараларыннан тыш, халык медицинасы да ярдәм итә.

✓ Көчле ютәл вакытында суган, сарымсак, җылы сөт, имбир, каз һәм бурсык мае, керән, борыч булыша.
✓ Аягыгызны горчицалы кайнар суга тыгып утырырга, аннары бурсык мае белән крем сөртеп, йон оекбаш киеп куярга, майны күкрәккә һәм аркага да сөртергә кирәк. Шуннан соң яхшылап төренеп ятарга киңәш ителә.
✓ Сарымсакны кайнар суга салып, ингаляция ясарга да мөмкин.
✓ Түбәндәге ысулның да ярдәме тими калмас. 1 стакан сөткә 1 чәй кашыгы бал, ярты чәй кашыгы сода, шикәр зурлыгындагы бер кисәк атланмай салып кайнатып, шуңа 1 йомырка сарысын кушып болгатырга һәм кайнар килеш эчәргә кирәк.

ИММУНИТЕТНЫ НЫГЫТА

Бер стакан кайнар суга 5–6 канәферне салып, бер сәгать төнәтеп, көн дәвамында җылы килеш эчәргә кирәк. Канәферне вакыт-вакыт чәйнәп йөрү дә файдалы. Ул йоткылык өстенә кергән вирусларны юк итәргә булыша. Лаванда, яшел чәй, әрем яки ак чыршы (пихта) эфир майлары сеңдерелгән кулъяулыкны иснәү дә файдалы. Янәшәгездәге кеше төчкерсә яки ютәлләсә бигрәк тә. Эш өстәленә берничә тамчы эвкалипт мае тамызу да зыян итмәс.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

ИСКЕ ОРЛЫКНЫ УЯТЫП БУЛА

Үзең әзерләгән яки кибеттән сатып алып, кайчангы икәне онытылган иске орлыкларны нишләтергә? Әлбәттә, сыналган, яратып үстерә торган сорт орлыкларны ташларга кул бармый. Мондый вакытта аларга бер шанс бирү дә комачау итмәс. Мәсәлән, помидор орлыклары 7 елга кадәр һәм хәтта артыграк та сакланырга мөмкин икән. Әлбәттә, барлык орлык та 100% тишелү турында сүз бармый монда. Кыскасы, әллә кайчангы орлыкларны, ташлаганчы, берничә төрле ысул белән «уятып» карарга була.

1 Иң гади ысулларның берсе – аракыга салып тоту. Бер чәркә аракыга орлыкларны салып болгатасың һәм 15–20 минут тотасың. Аннары агып торган суда яхшылап чайкап, утыртырга да мөмкин. Мондый «стресс» йокламаган орлыкларны уятырга сәләтле.

2 20 мл калий гуматын 250 мл су салып эретергә һәм орлыкларны 15–20 сәгатькә яки бер тәүлеккә әлеге катнашмага салып торырга. Мондый катнашмага салып тотканда гөл һәм куаклардан кисеп алган үсентеләр дә тизрәк тамыр җибәрә.

3 Үсүне тизләтә торган стимуляторлар да йоклаган иске орлыкларны уятырга сәләтле. Мәсәлән, «Эпин-Экстар» (100 мл суга 1–2 тамчы салып, 4–6 сәгать тотасы) һәм «Циркон» (10 мл суга 2 тамчы салып, 6–8 сәгать тотасы) кебек стимуляторлар иске орлыкны уятырга мөмкин.

4 Кайберәүләр орлыкны кайнар суга тиз генә салып алып та уятып була дип саный. Тик болай эшләгәндә аны пешерү куркынычы бар.

Кайчак орлыкның яраклылык вакыты чыкмаса да, тишелмәскә мөмкин. Бигрәк тә помидор, борыч, баклажан орлыклары. Ә бу – житештерүчеләрнең үзенә күрә бер сере: алар орлыкны тирән йокыга махсус талдыралар. Орлык озаграк саклансын өчен шулай эшләнә икән.

vk.com

Орлыклар тишелешен яхшырта торган халык ысуллары да бар. Моның өчен гадәттә бал, алоэ һәм көл кулланалар. Берничә ысул тәкъдим итәбез.

БАЛ
200 мл суга 1 чәй кашыгы бал салып болгатырга һәм орлыкларны шунда 5–6 сәгать тотарга. Аннары чайкарга һәм киптерергә кирәк.

АЛОЭ
Алоэның өч еллык аскы ботакларын кисеп алып, кара тѳстәге тукымага төрергә һәм пакетка салып, бер атнага суыткычка куярга. Аннары аның согын сыгып, су белән 1:1 күләмдә болгатып, шунда орлыкларны 15–20 сәгать тотарга. Әлеге ысул кыяр, кабак, борыч өчен килешми, ә помидор өчен менә дигән.

КӨЛ
1 л суда 2 аш кашыгы көлне болгатырга да 2 көн шуны тонәтеп тотарга. Аннары әлеге сыеклыкта марляны чылатып, орлыкларны шуңа төрергә һәм пакетка салып, 4–7 сәгать тотарга.

Белеп тор!

Тәме китмәсен

Тәмләткечләрне коры, караңгы җирдә, җылылык чыгара торган җиһазлардан һәм кояш нуры төшә торган урыннан ерактарак сакларга кирәк. Гадәттә, без, якын һәм уңайлы дип, тәмләткечләрне плитә янына куярга күнеккән, ә бу иң кулай урын түгел.

Төрле тәмләткечнең яраклылык вакыты төрлечә. Тәме дә шуңа бәйле рәвештә үзгәрә. Вакланган тәмләткечләрнең саклану вакыты – 6 ай, ә бөтеннәренеке – 2 елга кадәр. Вакланмаган дарчин, мөшкәт чикләвеге, канәфернең яраклылык вакыты 2 елдан да артып китә. Кориандрның вакланганын алмавың хәерле, чөнки вакланганының саклану вакыты бик аз.

Төелгән имбирне дә алуга кулланып бетерүең хәерле. Шуңа да аны сатып алганда берничә куллануда тотып бетерерлек итеп кенә алыгыз. Төелгән борычның исе һәм тәме тиз бетә. Шуңа да кара борычның төелмәгәнен сатып алып, үзең ваклап кулланууың яхшырак.

Укучы киңәше

ГӨЛ КАР СУЫ ЯРАТА

Мин күп еллар гөлләр өчен эрегән кар суы кулланам. Әллә ни ачыш ясадым димим, аның үсемлекләргә файдалы булуын инде әллә кайчан ачыклаганнар. Кар суы сипкән гөлләр тизрәк үсә, яхшырак ботаклана, сәламәт һәм матуррак күренә. Кар суын бигрәк тә яран, цикламен, бегонияләр ярата. Берничә тапкыр кар суы сипкәннән соң аларның чәчәкләре купшырак, таҗлары жетерәк була һәм озак коелмый. Игътибар иткәнегез бардыр: краннан алып сипкән судан соң гөл төбендә ак юешкын сыман нәрсә пәйда була. Әгәр елга яки инеш янында яшисез икән, гөлләр өчен шул суны кулланырга була. Ул да сыйфаты буенча кар суына охшаш.

Галимә ЗАРИПОВА. Арча

Исеңдә тот!

ГОРТЕНЗИЯГӘ АЛЮМИНИЙ КИРӘК

Гортензия чәчәгенең төсен үзгәртү өчен тылсымчы булырга кирәкми. Аңа махсус ашлама кертү дә җитә.

Эре чәчәкле гортензиянең төсе сорты на гына түгел, ә туфрагына (pH) һәм анда алюминий булуга бәйле. Алюминий ачы, фосфорга ярлы туфрак тарафыннан яхшырак үзләштерелә. Гортензия зәңгәр төстә булсын өчен, туфракка алюминий кертергә кирәк. Моның өчен су сипкәндә суда эри торган алюминий сульфатын (500 г/1 кв. м) кушып сибәргә киңәш итәлә. Әлеге катнашманы яфракларга тидерергә ярамый, бары төбенә генә сибегез.

Тәмле булсын!

Суши-торт

Гөлназ ГАНИЕВА рецепты

Кирәк: *250 г пешкән дөге, 2 бит нори, 250 г тозлы кызыл балык, 150 г эремчекле сыр, 1 кыяр (авокадо да өстәргә була), соя соусы һәм күнҗет.*

Суши-тортны 18х18ле квадрат яки 20 сантиметр диаметрлы формага катламлап тезәбез. Иң аска нори, аның өстенә пешкән дөгене тыгызлап җәябез. Бүлмә температурасында җылытылган эремчекле сырның яртысын дөге өстенә сылыйбыз. Аннары туралган кыярны тезеп, өстен нори белән каплыйбыз. Киләсе катламда – дөге, калган эремчекле сыр сылана. Ә иң өстенә балык тезеп, тыгызлау өчен өстенә учыбыз белән басабыз. Өстенә күнҗет сибәбез һәм суши-торт әзер! Аны юеш үткен пычак белән кисәргә киңәш ителә. Соя соусы сибеп ашарга мөмкин.

Хуҗабикәгә

5 соус

Нинди ризыкка тотынсак та, хәзер соус куллану киң таралган. Ул ризыкка эстетик матурлык бирүдән тыш, тәмле дә. Түбәндәге 5 төрле соус һәр хуҗабикә күңеленә хуш килер.

☑ 15 процентлы каймакка вакланган ике тырнак сарымсак, туралган укроп, тоз һәм борыч салып болгатырга. Мондый соус голубцы, кыздырган бәрәңге һәм яшелчә кәтлитләре өчен яхшы.

☑ Зәйтүн мае + лимон согы + тоз + кипкән базилик + тимьян. Соус яшелчә салатлары, балык, тавык, төрле итләргә бара.

☑ Сөт өсте (сливки) + сыр + мөшкәт чикләвеге + киптерелгән сарымсак. Сөт өстен табада җылытабыз да сыр һәм тәмләткечләрне салып, сыр эрегәнче утта тотабыз. Бу соус дөге һәм бәрәңгегә килешәчәк.

☑ Помидор + суган + сарымсак + бер чеметем кызыл борыч + тоз. Помидорны, тышчасын чистартып, тәмләткеч, тоз, суган һәм борыч белән блендерда изәргә. Әлеге соус мичтә пешкән бәрәңге, пешкән яшелчәләр, сыер һәм тавык ите белән ашарга тәмле.

☑ Эремчекле сыр + яшел тәмләткечләр + төелгән кара борыч + бераз гына тоз. Барысын бергә болгатырга да табынга балык, бәрәңге һәм пешкән яшелчәләр белән бирергә мөмкин.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

Илдар Мөхәммәтҗанов

БЕР СҮЗ ӨЗӘ АРАНЫ

Өйләнешкәндә берәү дә аерылам дип гаилә кормый. Әмма мөнәсәбәт җепләренең кинәт өзелүе дә бик мөмкин шул. Коръәндә аерылышу турында да, мөнәсәбәтләрне җайга салу турында да язылган. Бу юлы «талак» төшенчәсенә тукталырбыз. «Талак» сүзе нәрсәне аңлата? Ислам дине буенча аерылышу ничек булырга тиеш?

«Өметләләр» мәчете имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт САФИНнан шушы һәм башка сорауларга җавап белештек.

:: Иң элек «талак» төшенчәсенә аңлатма бирсәк иде.

– Гарәп телендә «талак» сүзе «җибәрү», «калдыру» дигән мәгънәне аңлата, ә шәригатьтә талак ул – ир-атның, никах килешүен юкка чыгарып, хатынын аерып җибәрүе. Гаиләне таркатып, хатын белән аерылу – бик җитди нәрсә. Шуңа күрә ир-ат талак әйткәнче бик нык уйларга тиеш. Әгәр дә ир белән хатын бер-берсен аңламасалар, яратмасалар яки холыклары туры килмәсә, Аллаһы Тәгалә аларга бу мәсьәләне талак юлы белән чишәргә рөхсәт итә.

:: Талак әйтүнең үз тәртибе бар. Шуның белән дә таныштырып узсагыз иде.

– Әйе, талак әйтүнең үз тәртибе бар, ләкин кызганыч ки, күп ирләр аны белмиләр. Ирләрнең күбесе аерылу өчен хатынга тоташтан өч тапкыр «талак» дигән сүзне әйтергә кирәк дип уйлый. Ә чынлыкта бу алай түгел. Бер тапкыр талак әйтеп тә хатын белән аерылырга була. Әгәр дә ир кеше хатынына берьюлы өч тапкыр «талак» яки «мин сине аердым» дисә, ул аны үзенә яңадан никах укытып та кире кайтара алмаячак. Моның өчен аның аерылган хатыны икенче иргә кияүгә чыгарга һәм аның белән якынлык кылып аерылырга тиеш. Шуннан соң гына ул, никах укытып, беренче иренә яңадан кияүгә чыга ала. Бу хакта «Бәкара» сүрәсенең 230 нчы аятендә аңлатыла. Аллаһы Тәгалә бу хөкемне ир кеше хатынына талак әйтер алдыннан мең кат уйласын өчен иңдергән. Гомумән, ир кеше үз гомерендә хатынына ике тапкыр гына талак әйтә ала. Әгәр дә өченче тапкыр талак дисә, ул аны гомерлеккә югалтачак. Аллаһы Тәгалә «Бәкара» сүрәсенең 229 нчы аятендә: «Хатынны кире кайтарырга рөхсәт итүче талак ике мәртәбә. Аннан соң хатынны кире кайтарып, хакларын үтәп яшәгез яки күркәм рәвештә аны аерып җибәрегез», – диде.

«Талак» сүрәсенең 1 нче аятендә аңлатылганча, аерылырга ниятләгән ир кеше «талак» сүзен хатыны күремнән чиста булган вакытта әйтергә тиеш. Аллаһ Тәгалә: «Әгәр дә хатыннарыгызны аерырга теләсәгез, аларны күремнән пакь вакытта талак кылыгыз һәм күрем вакытын санагыз», – дип әйтте. Ир кеше хатынына күрем вакытында талак дисә, бу талак санала, ләкин аңа моның өчен зур гөнаһ була. Әгәр дә ир кеше хатынына бер тапкыр талак дисә, ул аны өч күрем вакыты узганчы хәтле нихах укытмыйча кире кайтара ала. Әгәр дә ир кеше талак әйткәннән соң хатыны белән өч күрем вакыты узганчы дуслашмаса, алар аерылган булып исәпләнә.

:: Талакны ир-ат кына әйтә аламы? Нинди очракларда хатын-кызга да талак әйтү рөхсәт ителә?

– Гаиләне саклап калу өчен, Аллаһы Тәгалә талак әйтү хокукын бары тик ир-атка биргән. Ир-ат күбрәк акыл белән уйлап эш итә, ә хатын-кыз хискә бирелүчән. Талак әйткәнче, ир-ат әле ул кат-кат уйлый. Моннан тыш ир-ат гаилә башлыгы булып тора. Әгәр дә талак әйтү хокукы хатын-кызга бирелгән булса, ул ачуланган саен хискә бирелеп талак әйтер һәм гаиләләр бик тиз таркалыр иде. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә үзенең хикмәте белән хатын-кызга талак әйтү хокукын бирмәгән. Шәригатьтә хатын-кыз башка юл белән иреннән аерыла ала. Шуның берсе «хульг» дип атала. «Хульг» ул – хатын-кызның иренә билгеле бер күләмдә акча биреп яки алган мәһәрен кире кайтарып талак әйттерүе. Аллаһы Тәгалә бу хакта «Бәкара» сүрәсенең 229 нчы аятендә: «Әгәр сез ир белән хатынның гаилә мәсьәләсендә Аллаһның әмерләрен үти алмавыннан курыксагыз, хатынның ире аерсын дип биргән нәрсәсе өчен икесенә дә гөнаһ юк», – ди. Хәнәфи мәзһәбе галимнәре фикеренчә, бу очракта ир кеше хатыныннан биргән мәһәрен кире кайтаруны яки аның бәясен кайтаруны шарт итеп куя ала. Бервакытны Сәбит ибен Кайс исемле сәхабәнең хатыны Мөхәммәд пәйгамбәр янына килә дә иреннән аерылырга теләвен белдереп әйтә: «Йә Аллаһның илчесе! Мин иремнең холкыннан да, һәм диненнән дә риза, ләкин ямьсез булганга күрә аның хакларын үтәмәүдән куркам», – ди. Мөхәммәд (с.г.в.) аңа: «Син иреңә хөрмә бакчасын кире бирергә ризамы?» – ди. Ул: «Әйе», – ди. Шуннан соң Мөхәммәд (с.г.в.) Сәбит ибен Кайска: «Бакчаңны кире ал һәм бер тапкыр талак әйтеп, хатыныңны аер», – диде.

> Моннан тыш шәригатьтә хатын-кызның, казый янына барып, иреннән аеруны сорый алу хокукы бар. Ләкин моның өчен җитди сәбәпләр булырга тиеш. Мәсәлән, әгәр дә ир кеше хатынының хакларын да үтәмәсә, җәберләп яшәсә, матди яктан тәэмин итмәсә яки нәсел калдыра алмаса, хатын-кыз, казый янына барып, иреннән аеруны сорый ала.

:: Шаяртып кына талак әйтү – гөнаһмы?

– Әйе, гөнаһ. Аллаһы Тәгалә Коръәндә «Бәкара» сүрәсенең 231 нче аятендә: «Аллаһның Коръәндәге хөкемнәре белән шаярмагыз», – ди. Әле моның өстенә, шаяртып кына хатынга талак әйтү талак булып санала. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) әйтте: «Өч нәрсә чынлап һәм шаяртып әйтсәң дә санала. Алар: никах, талак һәм колны азат итү». Моннан тыш, исерек килеш һәм бик каты ачуланып талак әйтү дә талак булып санала. Әгәр дә ир-ат кеше йоклаган вакытта саташып «талак» дисә, бу талак булып саналмый.

:: Телефоннан, онлайн гына да талак әйтү дөрес саналамы?

– Талак әйтү өчен хатынның каршында басып торуы мәҗбүри түгел. Телефоннан, онлайн гына да талак әйтү дөрес санала.

:: Аерылмыйча, балалар хакына дип, иргә түзеп яшәгән өчен хатын-кызга савап бармы?

– Әйе, бар. Әгәр дә хатын-кыз балалар хакына иренең начар холкына сабыр итеп яшәсә һәм аның хакларын җиренә җиткереп үтәсә, ул бик зур әҗер-савапка һәм Аллаһның ризалыгына ирешә. Аллаһы Тәгалә Коръәндә «Зүмәр» сүрәсенең 10 нчы аятендә: «Бары тик сабыр итүчеләргә генә әҗер-савап хисапсыз бирелә», – дип әйткән.

:: Хәзрәт, ислам дине кагыйдәләре буенча аерылу процедурасы бик катлаулы бит. Бу – бәлки, гаиләләрне саклап калу, парларга уйлану өчен дә бер мөмкинлектер?

– Әйе, шулай. Коръәндә талак мәсьәләсе турында иңдерелгән хөкемнәр гаиләне саклап калуга юнәлдерелгән. Мәсәлән, ни өчен хатын-кыз ире талак әйткәннән соң өч күрем узганын көтәргә тиеш? Моның хикмәтләре бернича. Беренчесе: ир белән хатын-кызга уйланырга һәм дуслашырга вакыт булсын өчен. Өч күрем узганчы, ир кеше үкенеп, хатынын кире кайтарырга мөмкин. Икенчесе: хатын-кызның балага узганмы-юкмы икәне ачыклансын өчен. Әгәр дә аның балага узганы мәгълүм булса, ире аны шул вакыт эчендә кире кайтара ала. Гаиләне саклауга юнәлтелгән талак белән бәйле тагын бер мөһим нәрсә бар. Ул да булса – талак кылынган хатынның гыйддәт вакытны (өч күрем) узганчы ире белән бер йортта яшәве. Күп мөселманнар моңа җитди карамый. Кайбер хатыннар, ире талак әйткәннән соң өч күрем узганын көтмичә, ирне ташлап, әти-әнисе янына кайтып китә яки ирләре аларны куып чыгара. Бу – гөнаһлы, хәрам гамәл. Аллаһы Тәгалә «Талак» сүрәсенең 1 нче аятендә: «Раббыгыздан куркыгыз. Талак әйткәннән соң гыйддәт вакыты (өч күрем) узмыйча, хатыннарыгызны тора торган йортларыннан куып чыгармагыз һәм алар үзләре дә йортларын ташлап чыгып китмәсен», – ди. Аллаһы Тәгалә Коръәндә бу әмерне гаиләне саклап калу өчен иңдергән. Ир белән хатын талашканнан соң бер өйдә торса, алар, гафу үтенешеп, тизрәк дуслаша ала. Әгәр дә мөселманнар Коръәндәге Аллаһ хөкемнәре белән гамәл кылып яшәсә, күп гаиләләр таркалмыйча калыр иде.

Сорау – җавап

Каш йолку – гөнаһ?

Расүлебез (с.г.в.) тышкы кыяфәткә бернинди нигезсез үзгәртүләр кертүгә каршы булган. Чәч ялгау, тәнгә рәсем төшерү, теш кайрау, каш-керфек йолку Аллаһының рәхмәтеннән мәхрүм итәргә мөмкин дип кисәткән ул.

Каш йолкуның тыелган гамәл булуын хәдис тә дәлилли. «Кашларын йолкучыларга, йолкутучыларга Аллаһының ләгънәте булды», – диелә анда.

Белеп тор!

АЕРМАСЫ НИДӘ?

Дога ул – ялвару сүзләре. Аны үз телеңдә әйтергә дә, пәйгамбәрләр өйрәтеп калдырган сүзләр белән дә сорарга ярый.

Ә сүрә ул – Коръәндә килгән бүлекләр. Алар барлыгы – 114. Сүрәләр аятьләрдән тора. Кайбер аятьләр дога сүзләре буларак та бара.

(«Дин вә мәгыйшәт»)

Йәгез, бер дога!

БАШ АВЫРТКАНДА УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Бисмилләәһил-кәриим. Үә әгуүзү билләәһилгәзыйым миң шәрри күлли гиркыйн нәәри үә миң шәрри хәррин-нәәәр».

Мәгънәсе: «Рахман вә Рәхим булган Аллаһ исеме белән. Кәрим булган Аллаһ исеме белән. Һәртөрле авыруның зыяныннан һәм җәһәннәм уты начарлыгыннан бөек Аллаһыга сыенам».

Хикмәтле сүз

«Син ураза тотканда, синең белән бергә күзләрең, колакларың, чәчләрең, тәнең вә калган һәммәсе дә ураза тотсыннар».

«Догагыз булмаса, Раббы сезгә ни өчен игътибар бирсен?»

«Иң җинел гыйбадәт – дәшмәү һәм күркәм холык».

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

И туган тел, и матур тел...

Мин = милләт

Асыл

КАРИНА КАБДУЛЛИНА, КАЗАХ, 21 ЯШЬ

МИН ҺӘРВАКЫТ РОССИЯДӘ УКУ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНДЫМ. Казахстан башкаласыннан Казанга күчендем. Беренче карашка ят тоелган илнең мәдәниятенә, тормышына тулысынча керер китәргә, **«ҮЗ» БУЛЫРГА ТЕЛӘДЕМ.** Тора-бара, республикада яшәүче күп халыкларның тарихы белән таныштым. Аларның мөнәсәбәтен күрдем, үз милләтләренә булган кызыксынуларын, мәхәббәтен тойдым. **МИҢА, МИНЕМ ХАЛКЫМ ҺӘМ МИНЕМ ДӘҮЛӘТЕМӘ КАРАТА ДА ШУНДЫЙ УК ХӨРМӘТ ҺӘМ ЯРАТУ ХИСЛӘРЕ БАРЛЫГЫН СИЗДЕМ.** Шуны белә торып, әлбәттә, Казахстан һәм аның мәдәнияте турында күбрәк сөйлисе килү теләге уянды. Казанда исә безнең үз диаспорабыз бар икәнен белдем дә, ике дә уйламыйча, шуларга кушылдым.

ТАТАРСТАН МИНЕ ҮЗ МИЛЛӘТЕМНЕ ЧЫН-ЧЫНЛАП ЯРАТЫРГА, МӘДӘНИЯТЕМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНЫРГА ӨЙРӘТТЕ. Милли узаң, милли асылым нәкъ шул вакытта чагыла башлаган дип әйтә алам.

Көндәлек тормышта безнең халыкка хас киемнәр кия, бизәнү әйберләре тага башладым. Өйдә дә милли ризыкларны күбрәк пешерү һәм **КАЗАНДАГЫ ДУС-ИШЛӘРНЕ КУНАККА ЧАКЫРЫП СЫЙЛАУЛАР ЕШАЙДЫ.**

Ике ел элек Татарстандагы терлекләрне исәпкә ала һәм идентификацияли башладылар. Моңа кадәр эре хуҗалыклардагы мөгезле эре терлекләрнең колакларына тамга салсалар, быел шәхси хуҗалыклардагы малларга чират җитте. Бу эш нәрсә өчен кирәк һәм халык нәрсәне белеп торырга тиеш? Шул хакта аңлатабыз.

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Илдар Нугуманов сүзләре буенча, терлекләрнең колакларына электрон чипларны язгы-көзге ветеринария-профилактика эшләре вакытында салачаклар. Билгеле булганча, алар 1 февральдән башланып китте.

– Терлекләрне исәпкә алуның төп максаты – республикага документсыз, шикле терлекләрне керттермәү. Чөнки күршетирә республикаларда хайваннар арасында бик йогышлы, куркыныч авырулар бар. Икенчедән – һәр терлек турында мәгълүматлар базасын булдыру. Бу ветеринарларның да эшен җиңеләйтә, хуҗаларга да уңайлы булачак, – диде Илдар Нугуманов.

Аның әйтүенчә, биркалары булган терлекләрне генә сатарга һәм сатып алырга рөхсәт ителә.

– Әгәр республикага биркасыз терлек керә икән, аны карантинга ябарга һәм барлык авыруларга тикшерергә кирәк булачак. Андый сыерның сөтен сату, көтүгә чыгару тыела. Авыруларга тикшертү дә хуҗасына 4–5 мең сумга төшәчәк. Республикада ел саен моңдый 30лап очрак була. Алып кергән кешегә штраф та салынырга мөмкин. Ә биркасы булганда, бу мал турында мәгълүматны системадан карап, аның авырумы-түгелме икәнлеген ачыкларга мөмкин. Шуңа күрә шәхси хуҗалыклар документсыз, колагында тамгасы булмаган терлекләр сатып алуга бик сак карасыннар иде. Мал сатып алырга планлаштырганда, алдан хәбәр итәргә кирәк. Без терлек кайтарылачак республиканы, районны тикшереп, 4–5 көн эчендә җавап бирәбез. Башкача булганда, документсыз малларны кире кайтарырга туры киләчәк. Әйтик, узган ел шундый сарыкларны Башкортстанга кире илтеп куйдыртырга туры килде, – диде Илдар Нугуманов.

Сан

✓ Идентификацияләү өчен Татарстан бюджетыннан **58** млн сумнан күбрәк акча бүлеп бирелгән. Аларга **300** мең бирка сатып алынган. Биркалар өчен акча районнарга мөгезле эре терлек һәм шәхси хуҗалыклар санына карап бүлеп бирелгән.
✓ Бүгенгә республикадагы барлык мөгезле эре терлекләрнең **75** проценты «Хорриот» дип аталган бердәм системага кертелгән.
✓ **1** февральдән башлап бүгенгә кадәр шәхси хуҗалыкларда **8** меңнән артык мөгезле эре терлекне маркировкаларга өлгергәннәр.
✓ Татарстанда **900** меңнән артык мөгезле эре терлек бар, аларның **200** меңнән артыгракы – шәхси хуҗалыкларда.

«Шикләндерә...»

Барысын да үз күзләребез белән күрү өчен без Биектау районының Зур Көек авылына бардык. Районның ветеринария берләшмәсе җитәкчесе Илдус Вәлиев әйтүенчә, районда 16600 мөгезле эре терлек бар. Аларның 7 меңе – сыерлар. Шәхси хуҗалыкларда 3200ләп мөгезле эре терлек булса да, туачак бозауларны да исәпкә алып, 4700 колак алкасы бирелгән.

Зур Көек авылында безне Ләйсән һәм Илнур Гайнуллиннар хуҗалыгына алып керделәр. Аларның ун мөгезле эре терлеге бар. Шуларның өчесе – сыерлар. Тәүлегенә бер сыердан 24 литр сөт тапшыралар.

– Өйдә генә торып эшләргә күнектек инде хәзер. Җәен Битаман колхозына булышырга чыгам. Эшләгән өчен ашлыкны шуннан алам. Печәнне үзебез дә әзерлибез, сатып та алабыз. Терлек асрауның табышы юк, дип әйтмәс идем. Сөтен, итен сатып, акчасы кулга керә. Менә бу тамга кую шик тудырды. Алга таба салым салмаслар микән, дигән шөбһәле уйлар да кергәли. Барысын аңлатсалар да, күңелдәниндидер юшкын бар әле. Моның нәрсә икәнен белеп бетереп булмый бит. Тора-бара күренер инде, – дип елмайды ул.

Аның әйтүенчә, үзләре, туганнары өчен булган терлекне үз ишегалларында гына чалалар. Ә инде башка кешеләргә сатасы терлекне эшкәртү өчен чалу пунктына алып баралар.

Төп эшләр, әлбәттә, терлек абзарында барды. Мал табиблары башта терлекләрне туберкулезга тикшерде, кан алды, шуннан соң ике колагына да бертөрле булган уникаль саннар язылган биркалар кигерттеләр. Аларны махсус журналга язып алдылар, соңрак компьютерга кертәчәк. Әлеге саннар буенча терлек турында барлык мәгълүматны белеп булачак: туу вакытын һәм урынын, хуҗасы кем булуын, яшен, җенесен, нинди анализлар алынуын, токымын, кайчан бозаулаганын, нинди авырулар белән авырганлыгын һәм башкалар. Теге яки бу терлек турында мәгълүматларны белергә теләгән хуҗа кешегә мал табибына уникаль санны әйтү дә җитә.

Авылда яшәүчеләр арасында әлеге эшләрнең ни өчен башкарылганын төгәл белеп бетермәүчеләр дә бар.

– Нигә кирәктер, әйтә алмыйм. Безгә әйттеләр, ризалаштык. Димәк, шулай кирәк, – диде безгә ун мөгезле эре терлек, ат һәм сарыклар асраучы Халисә Хәйруллина. Үзенә – 64, ире Наил абыйга 67 яшь булса да, бик яратып карыйбыз терлекләрне, диделәр.

– Биш сыерны үзем савам. Әле менә берсе авырып киткәч, чалырга туры килде. Улыбыз һәм киленебез дә булыша, әлбәттә. Ләкин үзебез бер дә авырсынмыйбыз. Саулык барында, аяклар йөреп торганда китап укып кына өйдә ятып булмый бит. Йөрергә, хәрәкәтләнергә кирәк. Балалар орышса да, бабайга бик кирәк әле. Авылда яшәп, ничек мал асрамаска мөмкин, ди ул, – диде Халисә апа.

Фикер

Вилсур АЛИУЛОВ, «Шәле Агро» җәмгыятенең башкарма директоры:

– Яңалык һәрвакыт куркыта, шикләндерә. Минем үземнең дә халык арасындагы «салым салмасларммы, барысы да контрольдә булачак» дигән сүзләрне ишеткәнем бар. Ләкин чынлыкта исәбе булганда эшләү күпкә уңайлырак. Эшне алып бару өчен без аның нәтиҗәсен белергә тиеш. Ә аның өчен теләсә нинди җитештерүдә исәпкә алу мөһим. Ул юк икән, ул инде сукырларча эшләү була. Әлеге система безгә һәр хайван турында мәгълүмат алырга ярдәм итә. Элек фермаларда малларга үзебез генә сан куеп, буталып бетә идек. Ветеринар ниндидер процедура эшләргә килгәч, берничә сыерның бер сан белән билгеләнүе ачыклана иде. Ә бүген без аннан киттек. Һәр терлекнең үз исеме, саны бар, барлык мәгълүматы билгеле. Программалар ярдәмендә теләсә нинди эшне контрольдә тотып була. Һәм ул безгә яхшы табыш китерә, керемне күтәрә. Мин моны бик яхшы фикер дип саныйм. «Меркурий» системасына кушылып, продукцияне дә күзәтә алабыз. Анализ ясар өчен бик кулай.

ИДЕНТИФИКАЦИЯЛӘҮ ТУРЫНДА ТӨП 5 СОРАУГА ҖАВАП

Терлекләрнең колакларына чип куйдыртмаган очракта нәрсә була?
Биркасыз малларны итләтә яки башлата сатарга, сөтләрен тапшырырга, көтүгә куарга ярамаячак.

Хуҗалыкларның керемнә (сөт, ит саткан очракта) салым сала башламаслармы?
«Моннан куркырга кирәкми, – дип аңлатты Илдар Нугуманов. – Чөнки сөтләрен сата торган шәхси хуҗалыклар күптәннән «Меркурий» системасына кертелде. Шуңа күрә ит һәм сөт сатучыларга мал башына салымнар каралмаган».

Әлеге эшләр өчен халыкка акча түләргә туры киләчәкме?
Быел барлык хуҗалыкларда да бу эшләр бушлай башкарылачак. Киләсе елдан – түләүле. Терлек колагына куя торган тамганың бер комплекты 130 сумнан башлана. Моннан тыш, эшне башкарган мал табибына бер баш терлек өчен 100 сум тирәсе түләргә кирәк булачак.

Нинди терлекләрнең колакларына тамга салачаклар?
Быел мөгезле эре терлекләр (яңа туган бозаудан башлап) исәпкә алыначак. 2023 ел ахыры – киләсе елдан – атлар, сарыклар, кәҗәләр. Киләчәктә, законга үзгәрешләр кертелгән очракта, куяннар, дуңгызлар, кош-кортлар һәм умарта оялары да идентификацияләнәчәк.

Кайчанга кадәр дәвам итә?
Барлык төр терлекләр дә 2024 елның 1 мартына кадәр бердәм федераль системага кертелеп бетәчәк.

КҮҢЕЛЕҢ ГАРИП БУЛМАСЫН!

Алинә Хәйретдинованың шәхси архивыннан

Кайбычта яшәүче Алинә Хәйретдинова сүзләре бу. Гомер буе бер кул белән яши ул. Әмма бер дигән егеткә кияүгә дә чыга, балалар да үстерә. Берне түгел, дүртне бит әле! Башкалар бармак төртеп күрсәтмәсә, кулсыз икәнемне онытып та җибәрәм, ди.

– Бик көтеп алынган бала булганмын. Әни баштa өч малай алып кайткан, аннары соңлап кына мине тапкан. Әтуганда кулымны имгәткәннәр, – дип сөйли Алинә башыннан кичкәннәр турында.

Кая гына йөртмиләр кечкенә кызны... Тик дәвасын гына таба алмыйлар. Йөри торгач, кызга инвалидлык бирәләр. Әмма, кулы зәгыйфь дип, берәү дә иркәләп тормый аны. Үзе дә малайлардан ким булмый, агач башына да менә, биектән дә сикерә. Әнә шул шуклыгы гомер буе ярдәм итә инде аңа.

Әнисе бөтен эшкә өйрәтеп үстерә. Бәрәңгесен дә әрчи, чүбен дә утый, идәнен дә юа, хәтта сыер саварга да өйрәнә. Бер кулы икесе өчен дә эшли. Тырышлыкның бик иртә кирәге чыга. Кызга 17 яшь чагында, әнисе урын өстенә ята.

– Мин кечкенәдән җырларга яраттым. Гомер буе сәхнә дип яшәдем. Тели белсәң, теләк кабул була икән ул. Казан педагогия көллиятен тәмамлагач, бер ел балалар укыттым да мәдәният йортына эшкә кердем. Кайбыч сәхнәсе булса да, минем өчен Казанныкылардан да зур булып тоелды ул, – дип искә ала Алинә.

Өйдә урындыкка басып җырлаган Алинә, ниһаять, сәхнәдә тора! Мактау сүзләре аңа канат куя. Инде менә 22 ел шушы эшендә эшли ул. Башка җиргә барасы да килми, теләге дә юк. Йөрәгенә ял ала торган урын бит ул сәхнә! Булачак ире Фидаил белән дә шунда таныша.

– Бәрлебаш авылына концерт куярга барган идек. Фидаил мине шунда күреп калган. Соңрак ул Кайбычта дискотекалар уздыра башлады. Аралаша башладык. Туган көнем икәнне белеп, мотоцикл арбасына чәчәкләр тутырып алып килде ул. Ут сүнсә, шәм бирә, су бетсә, су китерә. Яратам дип күп сөйләшеп йөрмәде, эше белән күрсәтте. Озак очрашып йөрмәдек. Тәкъдим ясауга ук ризалаштым, – ди Алинә.

Әнисе аңа, пар эзләгәндә, үзе кебекне сайларга киңәш итә. Авыр сүз ишетергә, кимсенергә туры килмәсен, янәсе. Әмма чая Алинәнең фикере башка була: ник үзем кебекләр белән интегим, сау-сәламәт кешегә чыгам мин! Шөкер, Фидаиле кызның кимчелеген күрми дә. Туганнары да якын итәләр. Дөрес, сүз ишеттерүчеләр барыбер табыла. Тик Фидаил кеше сүзенә карап тормый. Алар матур итеп яши башлыйлар.

– Баштарак, өйләнешкән вакытта ирем, мине кызганып, кайбер эшләрне үзе эшли иде. Ашарга пешергәндә дә ярдәм итте. Бераздан әкренләп бар эш үземә калды. Ирем исә, и Алинәм, син бит сау-сәламәтләрне бер якка куясың, дип кенә әйтә иде. Мин иркәләнеп утыра торган хатын түгел. Бар эшне үзем эшләргә өйрәндем. Кулымның көче җитмәсә, теш белән ябышам, – ди Алинә.

Алар ире белән бер кыз, өч малай сөяләр. Инде Зәлинәләренә 17 яшь булган. Шушы балалары әниләрен үстерергә булышкан да инде. 3 яшендә үк, әнисенә ярдәм итәм дип, бала карашa башлаган. Икәү булгач, өченче туганнарын бергә караганнар. Дүртенчеләре тугач, сабый әнисенә эләкмәгән дә.

– Беренче бала тугач, бер кул белән кыенрак булды. Ул чакта ирем булышты. Аннары әкренләп өйрәндем мин. Шунысына сөенәм: иремнең беркайчан да кимчелегемне әйтеп, йөрәгемне яралаганы булмады. Рәхмәт аңа. Аның җылы мөнәсәбәте, яратуы, кадерләве миңа яшәр көч бирә, – ди Алинә. – Тормышта югалып калырга ярамый. Бәхет күктән төшми, үзең эзләп табасы, аны үз кулларың белән төзисе. Мин үземне бик бәхетле дип саныйм. Яраткан ирем, балаларым, гаиләм, эшем бар. Күңелем тыныч: якыннарым исән-сау. Минем кебекләр өйдән чыкмыйча кимсенеп ятмасын. Яшим дип яшәргә кирәк. Күңеле гарип булмаса, кеше синең кимчелегеңне күрми дә ул!

Алинә Махияновaның шәхси архивыннан

«МИН КИЛГӘНДӘ, ЙӨРӘГЕ ТУКТАГАН ИДЕ»

Алинә Махияновага – 26 яшь кенә әле. Чаллыдагы ветераннар госпиталендә эшли башлаганына нибары ике ай. Күптән түгел аңа үзенең белем һәм тәҗрибәсен көтелмәгән урында кулланырга туры килгән. Яшь табиб Уфадан Чабаксарга баручы ирне үлемнән алып калган. Исеме бөтен республикага танылган туташны без дә эзләп таптык.

Ул көнне Чаллы табиблары «ашыгыч ярдәм» машинасында бер авыруны Казанның 7 нче хастаханәсенә илткәннәр. Шуннан кайтып килгәндә, Мамадыш районы тирәсендә туктаган автобусны күреп алалар. Аның янәшәсендәге кешеләр аларны кул болгап ярдәмгә чакыра.

– Машина йөртүче Алексей Михеевка туктарга куштым да, чемоданымны тотып, киртәләр аша сикерә-сикерә, юлның икенче ягына йөгердем. М7 юлын беләсез, машина белән әйләнеп килсәң, бик күп вакыт уза. Ярдәм кирәк ир-атны җиргә сузып яткырганнар иде. Янындагы туганы аның хәле 15 минут элек начарланып китүен әйтте. Ул аңа беренче ярдәм күрсәтергә дә тырышкан. Ир-атка – 50 яшьләр тирәсе, пульсы юк, суламый да башлаган иде. Мин тизрәк ярдәм күрсәтә башладым. 5 минуттан йөрәге эшләп китте. Әмма аңына килмәде, – ди Алинә. – Машина йөртүчемә дә рәхмәт. Тиз арада җитәкчебез Васил Фәритович белән элемтәгә чыгып, юлдагы хәлне аңлаткан. Ул Мамадыш табиблары белән сөйләшеп, аларга әзерләнеп торырга кушкан. Без, авыруны машинабызга утыртып, Мамадышка чаптык.

Мамадыш хастаханәсендә дәваланган ират аякка басып, өенә кайтып киткән инде. Алинәгә Мамадыш районы хастаханәсенең баш табибы шалтыратып, рәхмәтен җиткергән. Авырып киткән ир-атның туганы да элемтәгә чыккан. Ни гаҗәп, Алинә аларның исемнәрен дә сорамаган.

Алинә – Чиләбе кызы. 5 нче сыйныфта укыганда ук, табиб булачагын белгән инде.

– Бөтен уй башыма да килмәде. Мәктәпне тәмамлагач, Башкортстан дәүләт медицина университетына укырга кердем. Аннан соң максатчан юллама буенча Чаллыга җибәрделәр, – ди кыю йөрәкле Алинә. – Әнием дә табиб булып эшли. Әтием – эретеп ябыштыручы. Миңа биргән тәрбияләре өчен аларга чиксез рәхмәтлемен. Мин бернинди дә герой түгел. Үз бурычымны үтәдем – бары шул гына.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

МӘХӘББӘТ ШИФАСЫ

Язмышка үпкәсе юк аның. Мөслим районының Вәрәшбаш авылында гомер итүче 63 яшьлек Зәкәрия Нәфыйков 39 ел инде үз аякларына басып йөрүдән мәхрүм. Яңа гына тормыш корган вакытта, бар хыяллары чәлпәрәмә килә аның. Басып торган баскычы белән бергә тормышы урталай сына.

– Ул көнне әле дә хәтерлим. 1984 елның 1 апреле иде ул. 24 яшем тулып киткән чак. Иринам белән алты айлык улыбызга сөенеп яшәп яткан вакыт. Бәла аяк астында, диюләре хак икән. Ишегалдындагы коены чистартырга төшеп харап булдым, – дип сөйли ул. – Коеның тирәнлеге 26 метр иде. Менеп җитәм дигәндә, баскычның бер аратасы сынды да, мин аска очтым. Әле өскә чыгарганда да берничә тапкыр төшереп җибәргәннәр.

Зәкәрия абыйны тиз генә хастаханәгә дә алып китә алмыйлар. Табиблар килеп җиткәнче, ике сәгать уза. Билдән аскы өлеше бөтенләй сизми башлый. Бары бер айдан соң гына 6 сәгатькә сузылган катлаулы операция ясала. Әмма табиблар артык өметләндерми.

– Без Ирина апаң белән бик яратышып өйләнештек. Берәү булса, миңа гарип ир нәрсәгә дияр иде. Ә ул тормышны берүзе тартты, – ди Зәкәрия абый.

Ирина апаның да әти-әнисе төпле була. Кияүләре белән күңелсез хәл булуга ук, кызларына үз киңәшен бирәләр. Кияүгә чыккансың икән, артка юл юк, авырлыкларны тигез итеп күтәрергә тиеш сез, диләр.

Табиблар, инвалид арбасыннан тора алмас, дисәләр дә, үҗәтлек үзенекен эшли. Даими күнегүләр ясау да бушка китми. Зәкәрия абый барыбер аягына баса. Чатанлап, култык таягы белән йөрергә өйрәнә. Улы Даниэль белән бергә тәпи китә алар. Әмма сынаулар моның белән генә бетмәгән икән.

– Тормыш өйрәтә икән ул. Чатанлап та, үрмәләп тә йөрдем. Ничек тә аякка басасым килде бит. Тик ике аяклы булып йөрү генә озакка бармады. 2006 елда мичкә аягымны терәп утырган идем, – ди ул. – Табибларның, аяк табанын кисик, дигәннәренә риза булмыйча йөрдем әле мин. Вакытны сузып, аяксыз да калдым. Бот төбеннән кистеләр аны. Әмма шулай да сер бирмәдем. Бер аяклы булсам да, култык таягы белән йөрергә тырышам. Бакчага чыксам, үрмәлим. Инде улым буй җитеп, үз гаиләсен корды. 2 оныгыбыз бар. Шул балабыз зур таяныч безнең.

Гаиләләрен чын мәхәббәт саклый аларның. Ул хисләр әле дә сакланган. Сөйләшүләреннән дә хөрмәт итүләре күренеп тора. Иринасы ирен кадерли, ире исә хатыны өчен ут яна.

– Мине карый-карый, Ирина апаң үзе дә авырып бетте инде. Гомер буе авыр эш аңа әлэкте бит. Фермада да эшләде, өйдә дә мәшәкать җитәрлек. Иринага әллә ничә операция булды инде. Тагын менә Казанга барырга җыена. Бер генә теләк – исән генә булсын иде! Төп терәгем бит ул минем. Әгәр ул булмаса, яши дә алмаган булыр идем, – ди Зәкәрия абый.

«ВТ» ГАЗЕТАСЫНЫҢ 105 ЕЛЛЫГЫНА МАХСУС ӘҢГӘМӘ.
БЕЗНЕҢ КУНАК – ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ РӘИСЕ, ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЫ РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА.

«МИН КУРКУЫМНАН КУРКАМ»

Илдар Мөхәммәтҗанов

Без нинди чорда яшибез? Киләчәгебез өметлеме? Килеп туган вазгыять милләт язмышына, әдәбиятына, гомумән, киләчәгенә ничек тәэсир итәчәк? Бу һәм башка проблемалар хакында Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Дәүләт Советы депутаты Ркаил ЗӘЙДУЛЛА белән сөйләштек.

:: Ркаил абый, Татарстан Дәүләт Советының соңгы сессиясенең тарихка кереп калачагы бәхәссез. Шәхсән үзегез үзгәрешләр шулай тиз булыр дип көткән идегезме?

– Безнең Конституциягә үзгәрешләр кертүне күптән таләп итәләр иде инде. Шулай булгач, аны көтелмәгән хәл дип әйтеп булмый. Бу мәсьәлә дистә ел дәвамында сузылып килде. Республика җитәкчелеге Россиянең яшәү рәвешендә федерализмның әһәмиятен бик яхшы аңлый. Һәм бүгенге казанышларыбыз да федерализм принципларыннан азмы-күпме файдалана белү аркасында булды. Бу бит инде Мәнди анасына да билгеле: республикалар, өлкәләр икътисадый яктан көчле икән, уртак дәүләт тә шулкадәр үк көчле була. Бөтен идарә җепләре дә башкала кулына тупланып беткәндә, моның нинди нәтиҗәләргә китерәсен тарихтан беләбез. Республика, РФ Конституциясенә теркәлгән дәүләт буларак, иң мөһим вәкаләтләрен югалтты. Моңа ни диясең? Инде республика җитәкчесенең атамасына килгәндә… Бүтән республикаларда ул атама күптән бетерелгән иде инде. Илдә бер генә президент булырга тиеш, дигән сүз, бер уйласаң, көлке яңгырый. Мондый дәлил буламыни? Һәр спорт клубының үз президенты бар! Мин мәктәптә укыганда бер тәртипле пионерны Интернациональ дуслык клубы президенты итеп билгеләләр иде. Соң, Татарстан Президенты белән Россия Президентларын кем генә бутый ала? Без аңлыйбыз, төптә, әлбәттә, Татарстанның, татар дәүләтчелегенең дәүләти атрибутларын тартып алу, символларыннан ваз кичтерү ята. Гомумән, милли республикаларның булуы гына да Мәскәү сәясәтчеләренең күбесенең эчен пошыра. Әйтерсең, Россия унитар дәүләт булса, өскә бәхет ишелеп төшәчәк! Без көрәшеп, тартышып карадык, әмма Мәскәү бит ул күз яшьләренә ышанмый. Алар көч-кодрәткә генә хөрмәт белән карый. Ә көч дигәнең бездә юк икән…

Замана катлаулы, әлбәттә. Тик бит бердәм булыр өчен бер-береңне хөрмәт итәргә дә кирәк. Кычытмаган җирне нигә кашырга? Хикмәт исемдә генә дә түгел. Инде «президент» сүзенә шул чаклы каныгалар икән, ярар, алыштырабыз; ахыр чиктә «рәис» тә шул ук мәгънәне аңлата. Иң мөһиме, аның вәкаләтләре булсын! Хәзер бит иң вактөяк мәсьәләләрне чишәр өчен дә Мәскәүгә йөгерәсе була: рөхсәт алырга, распатырга, килештерергә… Без моны совет вакытында бер үттек бит инде. Хәер, хәзер ул заманнардан да арттырып җибәрделәр бугай. Өтек автономия хокуклары да юк хәзер. Ә бит фаразлыйсы да юк: шөрепләрне кысу, боргычлау дәвам итәчәк.

Күреп торабыз: федерализм турында телгә алучы да юк бүген, юкса бит аның төп шарты – вәкаләтләрне чикләү, бер-береңә вәкаләтләр тапшыру.

Мин соңыннан булса да, сүз алып, үз фикеремне җиткердем. Бу инде ятып калганчы атып калу кебек кенә булды, әлбәттә. Ләкин эндәшми дә калып булмый иде.

:: Чыгышыгыздан соң сезне милли герой дип әйтүчеләр булды. Үзегез килешәсезме бу бәяләмә белән?

– Юк ла инде… Мин бит чыгышымда да, иманым камил, күбегез минем кебек фикер йөртә, дип әйттем. Ләкин аны чыгып әйтер өчен, бәлки, күпмедер кимәлдә кыюлык кына кирәктер. Мин сәясәтче түгел, фәкать шул гына. Депутатларның берсе: «Син ничек курыкмыйсың?» – дип сораган иде. «Мин дә куркам, билгеле. Тик мин куркуымнан куркам», – дип җавап бирдем.

:: Безнең киләчәк өметлеме?

– Өметсез – шайтан, диләр. Өмет иң соңыннан үлә, дип тә әйтәләр. Өметсез шайтан булып каласы килми, әлбәттә. Аннан соң дөнья куласа, әйләнә дә бер баса, диләр ич. Әле дөнья куләмендә әллә нинди үзгәрешләр булырга мөмкин. Гасырлар дәвамында татар яшәеше дәвам иткән икән (нинди генә фаҗигаләр кичермәгән безнең халык!), бүгенге сынауларны да исән-имин үтәрбез, иншалла. Ни генә әйтсәң дә, күбесе үзебездән тора. Умырткабыз сау булсын, без яңадан тураербыз. Төш, ядрә сакланса, халык теләсә нинди авырлыкларны да җиңеп чыга ул…

:: Җанисәп нәтиҗәләре хәлебезнең гаять аянычлы булуын күрсәтте…

– Халык кимүенең төрле сәбәпләре бар. Ләкин төп сәбәпләрнең берсе – барыбер балаларның аз туры. Хәзер бит авылларда да гаиләдә бер-ике бала. Нинди артым, үрчем турында сүз баруы мөмкин?! Без нәтиҗәләр дөрес түгел, өстәвенә пандемиянең дә үз өлеше булды, җан исәбен алучыларны өйгә кертмәүчеләр күп иде, дип күңелне юатырга тырышабыз анысы. Ләкин ул төп сәбәпләрдән түгел. Шул ук вакытта җан исәбен алуга төкереп карау да булмады түгел, булды. Милләтне билгеләгәндә «санаучылар» үзләрен бик иркен хис иткәнгә охшый. Бигрәк тә күрше-тирә өлкәләрдә. Демография законнары буенча алай ук кимергә тиеш түгел идек. Әлбәттә, ассимиляция соңгы егерме елда коточкыч кимәлдә артты. Милли мәгариф системасы җимерелү аңа шулай киң юл ачты. Ләкин бит элекке тәҗрибә күрсәткәнчә, инде урыслашкан, тамырыннан аерылган кемсә дә гадәттә үзен барыбер татар дип белдерә. Хәер, хәзер аларның балалары, оныклары инде ул атамадан да ваз кичәргә мөмкин.

Башкортстанда шулай ук татарның кимүе аңлашыла. Анда, минемчә, административ ресурс үз эшен эшли. Мин бу турыда бер әңгәмәдә сөйләгән идем инде, кабатлап торасым килми. Җанисәп алуны үз көенә куйсаң, яки берниндн тыкшыну булмаса, барысы да үз урынына утырачак. Безгә татарның татар, башкортның башкорт булып калуы кадерле. Алар да, безнең кебек үк, авыр заманнар кичерә, инкыйраз аларга да яный. Әмма аларда милли үзаң бездәгедән көчлерәк шикелле тоела. Шунысы гына кызганыч: ул күп очракта татарга карата каршылыкка корылган һәм бу идеология аяныч нәтиҗәләргә дә китерергә мөмкин. Тугандаш халыкларның дошманлашуыннан Аллаһ сакласын!

Ләкин Башкортстанда татарларның кимүе, башка төбәкләр белән чагыштырганда, ул кадәр үк куркыныч түгел әле. Чаманы белгәннәр! Сембер, Самара, Түбән Новгород, Свердловск, Пермь өлкәләрендә татарлар саны бик күпкә кимегән. Мөмкин хәлме бу? Әйткәнемчә, демография законнары моңа каршы килә. Менә шуннан сорау туа инде: бу ялган аларга нәрсә бирә? Хәтерегездәме, имеш, Сталин, кеше юк икән, аның проблемасы да юк, дигән бит, моны тулы бер халыкка карата да кулланырга мөмкин: халык аз санлы икән, аны санламаска да, милли-мәдәни ихтыяҗына игътибар итмәскә дә була. Нинди мәктәп? Нинди дәреслекләр? Нинди мәчет? Үз урыныгызны белегез! Шунысын да онытмаска кирәк: аз санлы халыклар бик тиз арада юкка чыга… Шуңа мин ачыктан-ачык әйтергә мәҗбүр: соңгы җанисәп алуда халкыбызның саны кимү илдәге бөекмәмләкәтчел шовинизмның артуына да турыдан-туры бәйле.

:: Киләчәктә халкыбыз язмышында Милли Шура кебек оешмалар нинди роль уйнаячак?

– Диванда ятып фәлсәфә сатучылар, «милләт өчен көрәшүче»ләр бик күп һәм алар татар конгрессын рәхәтләнеп сүгә. Бигрәк тә социаль челтәрләрдә, чөнки тышка да чыгып йөрисе юк. Соңгы еллардагы милли мәсьәләләргә кагылышлы митингларга ничә кеше чыга иде? Шул шул… Мин – конгрессның Милли Шурасы һәм бюросы әгъзасы да. Әлбәттә, бер оешма да камил була алмый, бөтен эшне башкарып та чыга алмый. Конгресс хәленнән килгәнчә тырышты. Ләкин ул бит халыкны артурыга турыдан-туры катнаша алмый! Әйе, без нәтиҗә ясарга тиеш. Конгресс эшчәнлегенә яңа сулыш кирәктер, мөгаен. Тик кайсы өлкәдә генә ул кирәкми?

Язучыларга килгәндә, Конгресс канаты астында без бик күп төбәкләрдә халык белән очраштык. Монда, әлбәттә, халык күңеленә күпмедер рух өстәү, әдәби сүз ишеттерү турында гына сүз алып барып була. Мәсәлән, безнең «великолепная тройка» – Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин Башкортстаннан кайтып кермәде диярлек. Дөрес, китапханәдә аз санлы халык белән очрашып, зур нәтиҗәләргә өмет итү сабыйлык булыр иде, зур залларда очрашу мөмкинлеге исә бирелми.

Ләкин ничек кенә сансызламасыннар, башкорт милләтчеләре нинди генә яңа ыру исемнәрен күтәреп чыкмасын, ул җирләрдә татар барыбер татар булып, башкорт исә үзе булып кала. Анда алар бер-берсен бик яхшы таный. Халык зирәк бит ул…

Конгресс эшен мин дә тәнкыйтьлим. Әмма тәнкыйтьләү җиңел ул, үзең эшләп күрсәтергә кирәк. Тәнкыйтьчеләр миннән башка да күп. Әлбәттә, әллә кайдагы Читаларда ансамбль әбиләренә милли костюмнар алып биреп кенә әллә кая ерак китеп булмый, яшьләр белән күбрәк эшләргә кирәк. Яшьләр белән эшләү мәсьәләсе шактый гына арткы планда кала бирә. Хәзер Милли Шура бюросында яшьләр белән эшләү секциясен оештырырга булдылар. Нәтиҗәсе ничек булыр, чөнки яшьләрнең игътибарын яулау, яшьләрдә милли үзенчәлеккә басым ясап, ниндидер үзгәрешләр кертү шактый авыр. Чын татар җанлы яшь активистлар җитми. Минем кебек кайбер картлар яшьләрне инертлыкта, үшәнлектә гаепләргә маһир. Минемчә, бу дөрес түгел. Актив яшьләр бик күп. Тик ул активлык күбрәк акча эшләүгә кайтып кала. Табигый. Җәмгыятьтә акча культы хөкем сөргәндә, милләт кайгысы артка чигенә. Аннан соң мәктәп мәсьәләсе бик мөһим. Татар теле һәм әдәбиятын предмет буларак та өйрәнмәгән кешедә татарлык ни дәрәҗәдә? Инде күбесенең әби-бабасы ук урыслашкан, гаилә тәрбиясе турында сүз дә юк. Татар җыры ишетсә дә хәтта чыраен сыта. Син аңа татарлыкны ничек аңлатасың? Дөрес, ниндидер могҗиза белән алар арасыннан да сирәк-мирәк гаҗәеп татар җанлы кешеләр килеп чыга. Үзе татарча белми, татар дип җан ата. Алар хәтта безнең ишедән милләтчерәк тә була, андыйларны да беләм. Тел белми дип, аларны читкә тибәрергә ярамый. Татар әдәбиятының күренекле әсәрләрен, публицистиканы урысчага тәрҗемә итеп, урыс телле татарларга җиткерергә кирәк. Күңелендә татарлык уянсын, бәлки, борынгы әби-бабайлар телен дә өйрәнә башлар… Мине наивлыкта да гаепләргә мөмкин. Ләкин яһүдләрнең XX гасыр тарихын искә төшерегез: бер наив кеше ике мең ел элек үлгән иврит телен өйрәнә башлый… Хәзер ул тел – Израиль дәүләтенең теле. Шунысын да онытмаска кирәк: яһүдләр үз идеологиясен теләсә нинди телдә алып бара: Германиядә – немец, Англиядә – инглиз, Россиядә – урыс телендә.

:: Язучылар берлегендә сез былтыр Әдәби тәрҗемә үзәген ачкан идегез. Эшләр ничек бара?

– Эшләр җайланып килә. Республика җитәкчелеге ярдәм итмәсә, үзебез генә әллә ни эш тә майтара алмас идек, билгеле. Мәсәлән, күптән түгел генә Төркиядә XX гасыр татар хикәяләре антологиясе нәшер ителде. Мин уйлыйм, төрек телендә китап чыгарабыз икән, ул Төркиядә нәшер ителергә, урыс телендә чыгарабыз икән, ул Мәскәүдә бастырылырга тиеш. Шул ук антология урыс телендә Мәскәү нәшриятында (ОГИ) басылып чыкты. Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» әсәре урыс телендә Мәскәүдә чыкты, хәзер шул ук нәшриятта типографиягә Әхәт Гаффарның хикәяләр җыентыгы китте. Безнең ниятләр зур.

:: Әсәрләрне тәрҗемәгә нинди принцип белән сайлап аласыз?

– Хәзерге заманга күбрәк игътибар итәргә тырышабыз, нәшриятлар да хәзерге заман язучыларын чыгару ягында. Ул теләсә нинди илдә шулай икән. Монда тагын бер шарт бар: әйтик, сайлап алган татар әсәре тәрҗемәдә укырга кызыклымы? Сәнгать ягыннан да шактый югары кимәлдә булырга тиеш, башка халыкка да кызык булырга тиеш. Бездә исә татарлар өчен генә язылган, үзара гына укып була торган әсәрләр шактый. Тарихка кагылышлы, шәхесләр турындагы әсәрләр кызыксыну уята. Мәсәлән, Төркиядә күптән түгел күренекле галим Надир Дәүләт вафат булды. Хатыны аның турында китап язган иде. Әле ул төрек телендә чыкмаган, без аны татар телендә бастырып чыгардык инде. Татарчага Төркиядә яшәүче милләттәшебез Раушания Алтай тәрҗемә итте. Хәзер шушы әсәрне төрекчәдән урысчага тәрҗемә иттек һәм ул шушы көннәрдә Мәскәүдә нәшер ителәчәк.

Азәрбайҗаннан шагыйрь Әкбәр Кошалы белән хезмәттәшлек итәбез. Ул Тукай шигырьләрен бик саллы китап рәвешендә Бакуда нәшер иткән иде. Аннары яшь шагыйрьләребезнең антологиясен азәрбайҗан телендә чыгарды. Хәзер исә Азәрбайҗанда татар хикәяләре антологиясе тәрҗемә ителә, без XXI гасырда язылган азәрбайҗан хикәяләрен татарчага тәрҗемә итәбез. Кунак ашы – кара-каршы, ди халкыбыз. Төрки халыклар арасында азәрбайҗан әдәбияты – бик кызыклы һәм бай әдәбият. Шулай ук төрек хикәяләре җыентыгын да татар телендә бастырырга исәп бар.

:: Язучылар берлегендә икенче ел рәис вазыйфасын башкарасыз. Сезгә бик катлаулы вакыт туры килде. Шушы вакыт аралыгында берлектә нинди үзгәрешләр булды?

– 4 мартта рәис булып сайлануга ике ел була. Үзем дә санап барам инде аны.

Рәис булып сайланганда эш планым тәкъдим ителгән иде. Шуларның 30 проценты гына гамәлгә ашса да, ул – бик зур нәтиҗә. Мин вәгъдә ителгәннең 30 процентын гына башкармаганмындыр дип уйлыйм.

Шәхсән үзем хуҗалык эшләре белән горурланам. Мин килгәндә түбәдән су үтә иде, түбәне көз көне үк яптырдык, хәзер подвалда зур эшләр бара, аннан икенче каттан башлап әчкә керәбез. Бинадан чыгып китмәс өчен, эшне этаплап алып барырга булдык. Ике күчү бер януга тиң, диләр бит, шундый югалтуларга дучар булмас өчен, әлеге юлны сайладык. Кайчак уңайсызлыклар була инде, нишлисең… Ләкин җыелышлар булып тора, Тукай клубы эшли. Берничә көн элек, мәсәлән, Йолдыз Шәрәпованың шигырьләрен укып ярышырга Казанның дистәдән артык мәктәбеннән, балалар бакчаларыннан бик күп балалар килгән иде. Яңадан мәктәпкә кайткандай тойдым үземне. Таныш гөрелте… Татар телендә!

Бу турыда мин озаклап һәм тәфсилләп сөйли алам, нәрсә яшереп торырга, мактанырга яратам инде…

:: Элек сез әйткән подвал гөрләп торган, диләр, анда редакцияләр эшләгән. Ремонттан соң бинада ниндидер үзгәрешләр буламы?

– Берлекнең үз нәшриятын булдырасыбыз килә. Бу хакта гариза да яздык инде. Моның үз кыенлыклары бар. Язучылар берлеге бинасы – тарихи һәйкәлләр исемлегендә. Шуңа күрә һәр үзгәрешне мәдәни мирас объектларын саклау комитеты белән килештереп эшләргә кирәк. Бюрократик киртәләр шактый вакытны ала. Нәшрият ул безнең зур эшебез булыр иде.

:: Бәлки китапның да бәясе төшәр иде.

– Әлбәттә. Аның максаты да шул инде. Татарстан китап нәшрияты чыгарган китапларның бәясе мине бик борчый. 800–900 сум – бик зур бәя. «Нигә алай?» – дип сорасаң, мең төрле сәбәп табалар. Дөресен әйткәндә, соңгы елларда нәшер ителгән китапларда редакцияләү дә бик нык аксый. Редактор бит ул – урысча әйткәндә, штучный товар. Аларны әзерләргә кирәк. Нәшриятта буыннар эзлеклелеге юкка чыгарылды. Яшьләр бит өлкәннәр арасында гына үз эшенең остасы булып әверелә.

> Гадәттә, безнең байларыбыз китап укымый. Китап укучы өлкән яшьтәге кешеләр, студентлар ул бәягә китапны сатып алмый. 12 мең сум пенсиягә яшәгән кешедә китап кайгысы булмавын да аңлыйм. Кайгысы да бардыр, тик аның ул кайгысы шатлыкка әйләндерергә матди чамасы юк. Китап укытуның төрле вариантларын уйларга кирәк. Электрон вариантка өстенлек бирергә дә инде вакыттыр.

:: Язучылар корылтаенда кабат үз кандидатурагызны куячаксызмы?

– Ул турыда уйлаганым да юк. Әле бит бирелгән вакытның яртысына гына җиттем. Яшьләрдән мине алыштырырлык кешеләр булса, нигә ябышып ятарга? Тулысынча иҗат эшенә китәргә дә ярый. Мин бит начар язучы түгел идем *(көлә)*.

Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе белән хезмәттәшлек итәбез. Үзем дә шул комиссиядә әгъза, Рөстәм Галиуллин да. Марат Әхмәтов булышлыгы белән моңарчы булмаган конкурс-бәйге үткәрдек. Инде шул ук бәйге яңадан башланды. Приз фонды гына да 7 миллион сумнан артык. «Татнефть» уртак конкурс үткәрү тәкъдиме белән чыкты. Озакламый мәдәният институты һәм Цифрлы үсешкә ярдәм итү ассоциациясе белән берлектә конкурс игълан итәбез.

> Конкурсларның булуы – үзе бер стимул. Моннан тыш балалар бакчалары, мәктәпләрдә укучылар белән очрашулар даими булачак. Бу – Мәгариф министрлыгы белән киңәшләшеп эшләнә торган эш. Әлеге очрашуларга йөрүче язучыларга гонорар түләү мәсьәләсен дә хәл иттек. Ярдәм итәргә торучы эшкуарлар да җитәрлек, шөкер.

:: Февральдә Тукай премиясе буенча фикер алышулар башлана. Күптән инде премия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертергә кирәк, дигән сүзләр ишетелә. Сезнеңчә, нинди үзгәрешләр кертергә кирәк?

– Иң беренче эш итеп аның суммасын арттырырга кирәк. Мин үз тәкъдимемне Рөстәм Миңнехановка яздым, ул риза булды. Тукай премиясенең күләме быелдан ике тапкыр арта, Аллаһ боерса, ягъни бер миллион сумны тәшкил итәчәк.

Туй үпкәсез булмый, әлеге премия тирәсендә ризасызлык һәрвакыт булды һәм булачак. Андыйларга мин генә ярдәм итә алмыйм. Премиягә тәкъдим итүнең үз кагыйдәсе бар, ул акка кара белән язылган, без аннан миллиметр да читкә китмәячәкбез.

:: Узган ел иң өлкән шагыйрә Флера Гыйззәтуллинага премия бирелмәү ризасызлык тудырды. Быел ул янә үз кандидатурасын куячаклары турында хәбәр итте. Аның өчен бу дулкынлануларның эзсез узмаячагын аңлыйсыздыр.

– Мин үзем дә Флера Гыйззәтуллинаны яңадан тәкъдим итү ягында. Туксан яшьтән узса да, аның әле энергиясе ташып тора, кулыннан каләме төшкәне юк. Әгәр без аңа бу премияне бирми калабыз икән, шәхсән миңа бик үкенечле булачак. Мин бит аны картайган кешегә матди ярдәм булсын дип тәкъдим итмим, ул – чыннан да зур шагыйрь. Аның «Коллык зинданы», «Яну дәверләрендә» поэмалары искиткеч. Бүтән әдәбиятларда поэма жанр буларак юкка чыгып бара. Аңа аерым бер төрле осталык кирәк. Флера апада ул бар. Аны самородок дисәң, үпкәли инде ул, ләкин төп хасиятен дә әйтми китә алмыйм: ул – искиткеч стихияле шагыйрь, сүз тылсымына ия; аңа бу сәләт Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән. Флера апа гомер буе эшләгән, ничә тапкыр премиягә тәкъдим ителеп тә, аңа бирелмичә калган, без бу хатаны төзәтергә тиеш. Дөрес, ахыргы сүзне идарә, аннары да премия бирү комиссиясе әйтәчәк.

> Кагыйдә буенча Тукай премиясе аерым бер әсәргә бирелә, ләкин шагыйрьнең иҗат юлы да исәпкә алынмый калмас… Менә әле генә Илһам Шакиров премиясен бирү комиссиясе утырышыннан кайттым. Анда да әлеге премия Флера Сөләйманова, Фердинант Сәлаховка үткән юлын, иҗатын исәпкә алып бирелде.

:: Премия, дип дулкынланабыз инде без, әмма киләчәктә татар китабын укучы калырмы соң?

– Ата-аналары гариза язса, мәктәптә ике-өч дәрес татар теле, әдәбиятын укый бала… Син миңа нинди сорау бирәсең? Әйтик, өйдә әлегә татарча сөйләшәләр дә ди, ләкин татарча сөйләшү әле ул китап укырга өйрәтү дигән сүз түгел. Балачакта китап укымаган кеше соңыннан укымый инде гадәттә. Мәктәп булмаса, әдәбият юк, укучылар булмаса, язучылар юк. Безнең хәлләр аяныч икәнне таныйрга кала. Ләкин, алдан әйткәнемчә, мин бит – өметен җуймый торган кеше. Кайчан да булса үләбез дип, хәзер үк егылып үләргәме? Дошман бит шуны көтә. Юк, без әле көрәшәчәкбез!

:: Тарих кабатланучан, диләр бит. Хәзерге вакыт тарихның кайсы чорына туры килә?

– Татар тарихының бер чорына да туры килми. Без иң аянычлы чорда. Монда могҗизага гына ышанырга кала. Заманнар үзгәреп, тарих кисәк борылыш ясаса гына… Әлбәттә, үзебез дә, алма, пеш, авызга төш, дип тик ятарга тиеш түгел.

:: Без – күндәм халыкмы?

– Без – бик күндәм халык. Күндәм, сабыр. Сабырлык турында күпме мәкаль генә бар. Халыкның менталитеты шунда күренә. «Сабыр төбе – сары алтын». «Сабыр иткән морадына җиткән». Бик бәхәсле мәкальләр. Дөрес, сабыр итеп морадына җитүчеләр дә бардыр, ләкин күбесе, морадына ирешмичә, сабырлыгын кочаклап үлеп тә китә.

:: Иҗатыгыз ни хәлдә?

– Әлмәттә бер язучы яши. Тормыш тәҗрибәсе бик бай, иҗаты бер китапка сыеп бетте. Аннан: «Иҗат ничек?» – дип сорыйлар икән. Бу, әйтмә миңа шул сүзне, дип ярсый башлый, имеш. «Иҗат» дигән сүзнең үзен күралмый башлаган! Чөнки инде яза алмый. Мин әле андый ук хәлдә түгел. Иҗат турында сорауларны тыныч кабул итәм *(көлә.)*

Башымда бер пьеса йөри. Әсәр бит ул иң әүвәл күңелдә языла, аннан соң гына кәгазьгә төшә.

Шигырьне исә күбрәк үзем өчен язам. Кайберләрен социаль челтәрләргә куям. Юбилей уңаеннан «Төштән соң» дигән китабым чыкты. Шунда соңгы елларда язылган шигырьләрем, робагыйларым да керде. Сатып алыгыз, дип әйтергә кыенсынам, чөнки бәясе – 720 сум…

Иң кызганычы, конкурсларда, бәйгеләрдә катнаша алмыйм, чөнки аларның барысында да диярлек мин – жюри әгъзасы. Казан мэриясе хикәяләргә ике телдә бер конкурс үткәрде, анда минем жюрига да, оештыручыларга да бернинди катнашым юк иде. Шуңа хикәя яздым, беренче урын булды, әлбәттә *(көлә.)*

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ӘҢГӘМӘНЕҢ ВИДЕОСЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Уены-чыны бергә

КӨФЕР УЙЛАР

- Киләсе тормышта без күпкә бәхетлерәк булачакбыз. Әмма, кызганыч, бу инде без булмаячакбыз.
- Ясалма йөрәк белән яшәүчеләр бар. Ясалма ашказаны белән яшәүчеләр турында әле ишеткәнем юк.
- Якын кешедән бүләк алгач, тартманы ачканда: «Хәтта иң якын кешең дә синең турында берни белми икән», – дип уйлап куясың.
- Чит ил мультфильмнарын карагач, «Автор ни әйтергә теләгән?» дигән сорау калмый.
- Иренезне игәүләмәгез. Иреге ул – сез утырган ботак.
- Әгәр дә актер пауза тота алмаса, мөгаен, ул – актрисадыр.
- Хатыныңның сүзен тыңламасаң, ул фокуслар күрсәтә башлый.
- Әгәр дә көннәрдән бер көнне бөтен хатын-кыз үз тәнен ничек бар шулай кабул итсә, дөньядагы бизнесларның яртысы шундук банкротка чыгар иде.

Әз-мәз мәзәк

– Ни өчен самолет машинага караганда куркынычсызрак?
– Чөнки очкыч белән профессионаллар идарә итә.

* * *

Ак канатлар бик нәзберек икән. Аларны юып, чистартып, киптереп торырга кирәк. Себерке күпкә уңайлырак: атландың да – әллүр!

* * *

Һава торышын әйткәндә, хәзер «фәлән градус салкын, әмма фәлән градус кебек тоела» дип әйтәләр. Бу саннар болай билгеләнәдер. Ике мужик балконга тәмәке тартырга чыга. «Бигрәк салкын, 10 градус бардыр», – дип әйтеп куя берсе. «Булыр сиңа! 15не күрсәтә!» – дип тәзәтеп куя аны икенчесе, градусникка карап.

* * *

– Кадерлем, син безнең мөнәсәбәтләрне саклау өчен нәрсә эшләдең?
– Мәсәлән, синең телефоныңны актармыйм.

* * *

Әгәр дә шансың миллионга бер икән, миллион тапкыр талпынып кара.

* * *

– Ит ашамасаң, 100 яшькә җитеп була, диләр.
– Нигә?
– Нәрсә нигә?
– Нигә кирәк алай озак яшәү?

* * *

Винни-Пух ул – егетме, кызмы? Ә Пятачок?

«БЕЗГӘ КИЛЕП КҮРЕГЕЗ!»

ВТ

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ КАРШЫНДАГЫ ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЯШӘҮЧЕ ХАЛЫКЛАР ВӘКИЛЛӘРЕНЕҢ ТУГАН ТЕЛЛӘРЕН САКЛАУ, ҮСТЕРҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ КОМИССИЯСЕ

И туган тел, и матур тел...

Һәр җирлекнең – үз асылы. Сөйләме дә үзгә, үз гадәтләре, бәйрәмнәре бар. Кешеләр һәм аларның яшәеше дә, кайда гомер кичерүләренә карап, бер-берсеннән аерыла. Ә сезнең авыл/шәһәр/район үзәге кешеләре бүген нәрсә белән яши? Сезгә килсәк, горурланып, нинәр күрсәтәчәксез? Ә иң мөһиме – сезнең җирлектә яшәүчеләр көндәлек тормышта татар телен ничек саклый? Авыл/шәһәрегезнең яшәеше һәм татар теленең көндәлек тормышта кулланылышын тасвирлаган видеоязмалар көтеп калабыз.

Гран-при 50 000 сум

ҖИҢҮЧЕЛӘРГӘ 25 000 сум ▶ Кызыксындыру бүләге 15 000 сум

ВИДЕО ТӨШЕР (хронометражы – 5 минутка кадәр, формат – горизонталь)

ҖИБӘР: **konkurs_vt@mail.ru**

ТАВЫШ БИРҮДӘ КАТНАШ: **vatantat.ru** **vatanimtatarstan**

Видеоматериаллар 10 майга кадәр кабул ителә
Сораулар булса: 8 (843) 222-09-64

Бәйгенең нигезләмәсе һәм шартлары

НОМИНАЦИЯЛӘР

- **10–17 ЯШЬЛЕКЛӘР** (1 җиңүче, 2 кызыксындыру бүләге)
- **18–34 ЯШЬЛЕКЛӘР** (1 җиңүче, 2 кызыксындыру бүләге)
- **35 ЯШЬ ҺӘМ ӨЛКӘНРӘКЛӘР** (1 җиңүче, 2 кызыксындыру бүләге)
- **ГРАН-ПРИ** (1 җиңүче)

Конкурста бер эш белән бер автор яки авторлык коллективы катнаша ала. Бәйге 2023 елның 23 гыйнварыннан алып 2023 елның 10 июненә кадәр үткәрелә.

6+

Беләсең килсә...

1 Элек ТНВда «Таяну ноктасы»н алып барган Алмаз Гафиятов хәзер кайда эшли?
а) «Рубин» футбол клубында;
б) «Зенит» волейбол клубында;
в) «Ак барс» хоккей клубында.

2 Бу илдә итальян теле дәүләт теле санала:
а) Бельгия;
б) Швейцария;
в) Мальта.

3 Пальма агачының ничә төре билгеле?
а) 1400;
б) 3400;
в) 4300.

4 «Хуа ниу» сорты алмалары нинди төстә?
а) кара;
б) ак;
в) зәңгәр.

Җаваплар: 1. в); 2. б); 3. б); 4. а).

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 15277 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 220

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+